# ТАТАРСТАН
# ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
# ҖЫЕЛМА БАСМАСЫ

*№ 1*
*гыйнвар*
*2013*

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
РӘСМИ БАСМАСЫ
Казан
2013

ЯЗЫЛУ ИНДЕКСЫ  78696
**ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ҖЫЕЛМА БАСМАСЫ:**
Татарстан Республикасы Дәүләт Советы рәсми басмасы

Формат $60x84^{1}/_{16}$. Тираж 95 экз.

© Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, 2013

Эчтәлек

# I
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАБУЛ ИТКӘН ЗАКОННАР ҺӘМ КАРАРЛАР


1. «Татарстан Республикасы дәүләт теле буларак татар телен куллану турында» *Татарстан Республикасы Законы* ....19
2. «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» *Татарстан Республикасы Законы* ..24
3. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 2.2 статьясына үзгәреш кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ...25
4. «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законының 30 һәм 38 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ....27
5. «Латин графикасы нигезендә татар алфавитын торгызу турында» Татарстан Республикасы Законының үз көчен югалтуын тану хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ....28
6. «Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында» *Татарстан Республикасы Законы* ....28
7. «Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистры турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 4 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* .......31
8. «Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ....32
9. «Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2013 елның язгы сессиясе секретариаты турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ....41

10. «Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2013 елның язгы сессиясе регламент төркеме турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ....42
11. «Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2013 елның язгы сессиясе электрон системадан файдаланып тавыш бирүне тикшереп тору комиссиясе турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ....43
12. «Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2013 елның язгы сессиясе редакция комиссиясе турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ....43
13. «Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз җиденче утырышы көн тәртибе турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ....44
14. «Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкилләре турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ....49
15. «Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында» 457-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ....49
16. «Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы хакында (457-4 номерлы проект)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ....50

17. «2013 елга, 2014 һәм 2015 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 454-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........51
18. «2013 елга, 2014 һәм 2015 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (454-4 номерлы проект)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........51
19. «Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредитлары бирү турындагы килешүләргә өстәмә килешүләрне раслау хакында» 455-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........52
20. «Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредитлары бирү турындагы килешүләргә өстәмә килешүләрне раслау хакында» Татарстан Республикасы законы турында (455-4 номерлы проект)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........52
21. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы хакында (1428-4 номерлы проект)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........53
22. «Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (2391-4 номерлы проект)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........53
23. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 2435-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........54

24. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (2435-4 номерлы проект)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ....................54
25. «Яшьләр һәм Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәте турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 6419-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ....................55
26. «Муниципаль хезмәт турында 1448-4 номерлы Татарстан Республикасы кодексы проекты хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ....55
27. «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең уңдырышлылыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 16 статьясына үзгәреш кертү хакында» 453-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ....................56
28. «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең уңдырышлылыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 16 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (453-4 номерлы проект)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ....................56
29. «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 456-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ..............57
30. «2012 елда Татарстан Республикасы Хисап палатасы эше турында хисап хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ....................58
31. «Россия Федерациясе Конституция Судына Россия Федерациясе Граждан процессуаль кодексының 26 статьясындагы беренче өлешенең 2 пункты, 251 статьясындагы беренче, икенче һәм дүртенче өлешләре, 253 статьясындагы икенче һәм өченче өлешләре нигезләмәләренең конституциячеллеген тикшерү ту-

рында гарызнамәне кире алу хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* .....................59

32. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 14.43 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ....59
33. «Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 343 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 195229-6 номерлы федераль закон проекты турында (руханилар, дини персонал һәм дини оешмалар хезмәткәрләренә, шулай ук күрсәтелгән вазыйфаларга кандидатлар өчен таләпләр билгеләү хокукын дини оешмаларга бирү өлешендә)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* .......61
34. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 5.63 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 168733-6 номерлы федераль закон проекты турында (административ хокук бозулар составларын төгәлләштерү өлешендә)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ...........................61
35. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 181965-6 номерлы федераль закон проекты турында (юл хәрәкәте өлкәсендә хокук бозуларны кабат кылган өчен җаваплылыкны көчәйтү турында)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ..............62
36. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 200753-6 номерлы федераль закон проекты хакында (Россия Федерациясендә торак урыннарында затларны фиктив теркәү өчен алшартларны бетерү максатларында һәм торган урында яисә яшәгән урында Россия гражданнарын теркәү кагыйдәләрен бозган өчен һәм аларның Россия Федерациясендә торак урыннарында теркәлмичә яшәгәннәре өчен административ җаваплылык билгеләү турында, шулай ук Россия гражданнарын торган урында яисә яшәгән урында

Россия Федерациясендә фиктив теркәгән өчен һәм Россия Федерациясендә чит ил гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган затларны торак урыннарында миграция исәбенә фиктив алган өчен җинаять җаваплылыгын билгеләү турында)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* .............................63

37. «Россия Федерациясе Җинаять кодексының 169 һәм 171[1] статьяларына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Башкортостан Республикасы Дәүләт Җыелышы – Корылтаеның закон чыгару инициативасы хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* .....64

38. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 20.25 һәм 28.3 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Алтай Республикасы Дәүләт Җыелышы – Эл Корылтаеның закон чыгару инициативасы турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* .....................................65

39. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Ставрополь крае Думасының закон чыгару инициативасы турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* .................................................................65

40. «Россия Федерациясе Граждан кодексының өченче өлешендәге 1151 статьясына үзгәреш кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Удмурт Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ................................................66

41. «Электрон имза турында» Федераль законга үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Пермь крае Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ...67

42. «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль законның 21 статьясына үзгәреш кертү хакында» 182753-6 номерлы федераль закон проекты турында (инвалидларны эшкә урнаштыру өчен квота бирелгән эш урыннары санын исәпләгәндә оешма хезмәткәрләренең санын авыр эшләр, зарарлы һәм (яисә) хәвефле һәм башка аерым хезмәт шартлары булган эшләр башкару белән шөгыльләнүче хезмәткәрләр санына киметү өлешендә)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* .......................67
43. «Хезмәткә сәләтсез гражданнарны караучы эшләмәүче затларга компенсация түләүләрен җайга салучы гамәлдәге норматив актларны үзгәртү мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министры М.А. Топилинга Оренбург өлкәсе Закон чыгару Собраниесе депутатлары мөрәҗәгате турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ......68
44. «Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләрнең финанс ягын хәл итү турында» Федераль законның 20.1 статьясына үзгәреш кертү хакында» 185943-6 номерлы федераль закон проекты турында (бурычларны каплауны кичектерү срогын арттыру өлешендә)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* .........69
45. «Россия Федерациясе Җир кодексының 28 статьясына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Карелия Республикасы Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ................................................69
46. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 177474-6 номерлы федераль закон проекты турында (даими рәвештә пассажирлар йөртү өлкәсендә муниципаль контроль турында)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ..........................................................................70
47. «Россия Федерациясендә чит ил гражданнарының хокукый хәле турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 184699-6 номерлы федераль закон

проекты турында (Россия Федерациясендә чит ил гражданы яисә гражданлыгы булмаган зат белән хезмәт шартнамәсен төзү рөхсәт ителгән яшь критерие буларак 18 яшьне билгеләү турында, шулай ук чит ил гражданына яисә гражданлыгы булмаган затка Россия Федерациясендә эшләүгә рөхсәт бирүдән яисә физик затларда хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыру хокукына патент бирүдән баш тарту йә аларда булган рөхсәтне яисә патентны юкка чыгару өчен өстәмә нигез буларак чит ил хезмәткәренең 18 яшькә җитмәвен күрсәтүне билгеләү хакында)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ....71

48. «Рәсми спорт ярышлары нәтиҗәләренә хокукый каршылыклы йогынтыны булдырмау максатларында «Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 200769-6 номерлы федераль закон проекты турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ....72

49. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 176205-6 номерлы федераль закон проекты турында (муниципаль контрольне гамәлгә ашыру өлкәсендә закон таләпләрен бозган өчен административ җаваплылык билгеләү хакында)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ....72

50. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 12.15 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 187796-6 номерлы федераль закон проекты турында (транспорт чарасының транспорт юлы өлешендә урнашуы, каршыга килгәндә юл бирешү яисә узып китү кагыйдәләрен бозган өчен җаваплылыкны көчәйтү турында)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ....73

51. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Х.Г. Миргалимов гарызнамәсе турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ....74

## II
## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЛАРЫ

52. «Татарстан Республикасы Дәүләт гимны текстының иң яхшы проектына конкурс үткәрү буенча комиссия эшенең йомгаклары турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ....................75
53. «Татарстан Республикасында балалар сәламәтлеген саклау турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ....................76
54. «Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз җиденче утырышын чакыру турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ....................82
55. «Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз җиденче утырышы каравына кертелүче мәсьәләләр турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ....................83
56. «2013 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советы эшен оештыру буенча чараларның якынча планы турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ....................86

## III
## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЛАРЫ ҺӘМ БОЕРЫКЛАРЫ

57. «Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ....................87
58. «Татарстан Республикасының Атказанган төзүчесе» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ....................87
59. «Татарстан Республикасының Атказанган табибы» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ....................88
60. «Татарстан Республикасының Атказанган торак-коммуналь хуҗалыгы хезмәткәре» дигән мактаулы исем

бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ....89
61. «Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ....89
62. «Татарстан Республикасының Атказанган укытучысы» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ....90
63. «Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ....90
64. «Татарстан Республикасының Атказанган физик культура хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ....91
65. «Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга иминлексезлегә сәбәпле урнаштырылган карантинны бетерү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ....91
66. «Татарстан Республикасы Президентының «1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 70 еллыгын бәйрәм итү турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ....94
67. «Татарстан Республикасының Атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ....95
68. «Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ....95
69. «Татарстан Республикасының Атказанган халыкны социаль яклау хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ....96
70. «Татарстан Республикасының Атказанган юристы» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ....96

71. «М.Я. Моратов турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ....................97
72. «Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ....................97
73. «Татарстан Республикасының Атказанган юристы» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ....................98
74. «Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ....................98
75. «Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ....................99
76. «Татарстан Республикасының Атказанган эчке эшләр органнары хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ...99
77. «Татарстан Республикасының Атказанган архитекторы» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ....................100
78. «Татарстан Республикасының Атказанган юристы» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ....................100
79. «Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ....................101
80. «Татарстан Республикасының Атказанган халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсе хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ....................101
81. «Татарстан Республикасының Атказанган халыкны социаль яклау хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ....................102
82. «Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ....................102

83. «Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ..................................103
84. «Татарстан Республикасының Атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ................103
85. «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты структурасына һәм Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* .......104
86. «А.М. Терентьевны Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесе итеп билгеләп кую турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ..................................................................112
87. «Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ..........................................................113
88. «Татарстан Республикасының Атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ....................................115
89. «Татарстан Республикасының Атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* .....................................115
90. «Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ...............................115
91. «Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ......................116
92. «Татарстан Республикасының Атказанган юристы» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* .......................................116

93. «Татарстан Республикасының Атказанган юристы» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ......................117
94. «Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга иминлексезлеге сәбәпле урнаштырылган карантинны бетерү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ................................118
95. «Татарстан Республикасының Атказанган ветеринария табибы» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ...........119
96. «Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ...............................................120
97. «Татарстан Республикасының Атказанган юристы» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ..................120
98. «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ....................................................................121
99. «Татарстан Республикасының Атказанган мелиораторы» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ......................123
100. «Татарстан Республикасының Атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ....124
101. «Т.Д. Нагумановны Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил итеп билгеләп кую турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ....124
102. «Дәүләт, шул исәптән хәрби, һәм дәүләт аккредитациясенә ия дәүләтнеке булмаган мәгариф учреждениеләре аспирантлары, адъюнктлары, студентлары, курсантлары һәм укучылары өчен Татарстан Республикасының махсус дәүләт стипендияләрен билгеләү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ...............................................................125

103. «Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ....................131
104. «Татарстан Республикасының Азнакай районы Мәндәй авылы территориясендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ....................131
105. «Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ..........133
106. «Татарстан Республикасының «Ана даны – Материнская слава» медале белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ....................134
107. «Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ....................135
108. «Татарстан Республикасының Атказанган төзүчесе» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ....................135
109. «Татарстан Республикасының Атказанган укытучысы» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ....................136
110. «Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ....................136
111. «Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ....................137
112. «Татарстан Республикасының Атказанган укытучысы» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ....................137
113. «Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ....................138

114. «Татарстан Республикасының Атказанган халыкны социаль яклау хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ....................................................................138
115. «Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ................................139
116. «Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* .......................139
117. «Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* .....................140
118. «Өч миллиард тонна Татарстан нефтен чыгару уңаеннан» медале белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ...................141
119. «Өч миллиард тонна Татарстан нефтен чыгару уңаеннан» медале белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* .....................141
120. «Өч миллиард тонна Татарстан нефтен чыгару уңаеннан» медале белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* .......................142
121. «Татарстан Республикасының Атказанган транспорт хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ...142
122. «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ..................................143
123. «Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ..........................................143
124. «Татарстан Республикасы Президентының аерым указларының үз көчләрен югалтуларын тану турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ...144
125. «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр буенча совет төзү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ..................................................................145

126. «Татарстан Республикасы Атказанган эчке эшләр органнары хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ...152
127. «Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирү турында» *Татарстан Республикасы Президенты Указы* ....................................152
128. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........153
129. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........153
130. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........154
131. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........154
132. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........154
133. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........155
134. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........155
135. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........155
136. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........156
137. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........156
138. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........157
139. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........157
140. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........158
141. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........158
142. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........159
143. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........159
144. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........159
145. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........160
146. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........160
147. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........160
148. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........161
149. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........161
150. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........162
151. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........162
152. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........163
153. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........164
154. *Татарстан Республикасы Президенты боерыгы* ..........164

# I
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАБУЛ ИТКӘН ЗАКОННАР ҺӘМ КАРАРЛАР

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 1. Татарстан Республикасы дәүләт теле буларак татар телен куллану турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 24 декабрендә
кабул ителде

Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә Татарстан Республикасында рус һәм татар телләре Татарстан Республикасының бертигез дәүләт телләре статусына ия.

Әлеге Закон Татарстан Республикасының бөтен территориясендә дәүләт теле буларак татар теленең кулланылышын тәэмин итүгә, дәүләт теле буларак татар телен куллануга гражданнарның хокукын тәэмин итүгә, татар тел культурасын яклауга һәм үстерүгә, татар халкы язуының тарихи традицияләрен дәвам иттерүне саклауга юнәлдерелгән.

**1 статья**

1. Дәүләт теле буларак татар теленең статусы «Россия Федерациясе халыклары телләре турында» 1991 елның 25 октябрендәге 1807-1 номерлы Россия Федерациясе Законы, башка федераль законнар, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» 1992 елның 8 июлендәге 1560-XII номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары белән билгеләнгән өлкәләрдә аны куллану мәҗбүрилеген, яклауны һәм аңа ярдәм итүне, шулай ук дәүләт теле буларак татар телен куллануга гражданнарның хокукын тәэмин итүне күздә тота.

2. Дәүләт теле буларак рус теленең статусы, аны куллану тәртибе һәм өлкәләре «Россия Федерациясе дәүләт теле турында» 2005 елның 1 июнендәге 53-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе халыклары телләре турында» 1991 елның

25 октябрендәге 1807-1 номерлы Россия Федерациясе Законы, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» 1992 елның 8 июлендәге 1560-XII номерлы Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнде.

**2 статья**

1. Дәүләт теле буларак татар телен куллануга гражданнарның хокукын тәэмин итү түбәндәгеләрне күздә тота:

1) дәүләт һәм муниципаль мәгариф учреждениеләрендә белемне татар телендә алу;

2) Татарстан Республикасы дәүләт органнарында, Татарстан Республикасы учреждениеләрендә, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарында мәгълүматны татар телендә алу;

3) республика һәм муниципаль массакүләм мәгълүмат чаралары аша, шул исәптән дәүләт теле буларак татар телендә мәгълүмат тарату өчен гамәлгә куелган басмалар челтәре аша, татар телендә мәгълүмат алу.

2. Дәүләт теле буларак татар телен куллануга гражданнарның хокукын тәэмин итү законда билгеләнгән башка рәвешләрдә дә гамәлгә ашырыла.

**3 статья**

1. Дәүләт теле буларак татар теле алфавиты, «Россия Федерациясе халыклары телләре турында» 1991 елның 25 октябрендәге 1807-1 номерлы Федераль законның 3 статьясына таянып, кириллица графикасы нигезендә төзелә.

2. Татар теле алфавиты «Татар алфавитын тәртипкә китерү турында» 1997 елның 20 гыйнварындагы 997 номерлы Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнде.

**4 статья**

1. Дәүләт теле буларак татар телен кулланганда хәзерге татар әдәби теле нормаларын, татар орфографиясе һәм пунктуациясе кагыйдәләрен раслау тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән тәртипкә түбәндәгеләр керергә тиеш:

1) дәүләт теле буларак татар телен кулланганда хәзерге татар әдәби теле нормаларын үз эченә ала торган грамма-

тикалар, сүзлекләр һәм белешмәләр исемлеге (экспертиза нәтиҗәләре буенча);

2) дәүләт теле буларак татар телен кулланганда хәзерге татар әдәби теле нормаларын үз эченә ала торган грамматикаларга, сүзлекләргә һәм белешмәләргә экспертиза ясау тәртибе;

3) дәүләт теле буларак татар телен кулланганда хәзерге татар әдәби теле нормаларын үз эченә ала торган грамматикаларга, сүзлекләргә һәм белешмәләргә экспертиза ясый торган югары уку йортлары һәм башка оешмалар исемлеге.

3. Дәүләт теле буларак татар телен кулланганда хәзерге татар әдәби теле нормалары дигәндә дәүләт теле буларак татар телен куллану өлкәләрендә тел чараларының һәм аларны куллану кагыйдәләренең җыелмасы аңлашыла.

**5 статья**

1. Рәсми эш башкаруда, рәсми язышуда, шулай ук телләр аша аралашуның Россия Федерациясе законнары нигезендә хокукый җайга салынырга тиешле башка өлкәләрендә татар теле кириллица графикасы нигезендә кулланыла.

2. Татарстан Республикасы дәүләт органнарына, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына гражданнардан, оешмалардан татар телендә латин яисә гарәп графикасында язылган мөрәҗәгатьләр кергән очракта, җаваплар татар телен кириллица графикасы нигезендә кулланып бирелә. Рәсми җавапка татар телендә латин яисә гарәп графикасы билгеләрен кулланып язылган җавап кушылып бирелергә мөмкин.

3. Татарстан Республикасы дәүләт органнары, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары эшчәнлегендә татар телендә латин яисә гарәп графикасында язылган документлар һәм материаллар белән эш иткәндә татар лексемаларын, исемнәрен һәм атамаларын дөрес итеп транслитерацион бирүне тәэмин итү максатларында әлеге Закон кушымтасы нигезендә татар теленең кириллица графикасы нигезендәге алфавиты хәрефләре латин һәм гарәп графикалары билгеләренә туры китереп кулланыла.

4. Татар теленең кириллица графикасы нигезендәге алфавиты хәрефләренең латин һәм гарәп графикалары билгеләренә туры килүен билгеләгәндә тел чараларын куллану кагыйдәләре, шулай ук аларны Татарстан Республикасы дәүләт органнары, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары эшендә әлеге Закон белән җайга салынмаган өлешендә куллану тәртибе

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

**6 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үз норматив хокукый актларын әлеге Законга туры китерергә, шулай ук әлеге Законда каралган Татарстан Республикасы норматив хокукый актларын кабул итүне тәэмин итәргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 елның 12 гыйнвары
№ 1-ТРЗ

«Татарстан Республикасы дәүләт теле
буларак татар телен куллану турында»
Татарстан Республикасы Законына
кушымта

## Татар теленең кириллица графикасы нигезендәге алфавиты хәрефләренең латин һәм гарәп графикалары билгеләренә туры килүе

| № | Кириллица нигезендә татар алфавиты хәрефләре | Билгеләр | |
|---|---|---|---|
| | | латин графикасы | гарәп графикасы |
| 1. | А, а | A, a | ئا |
| 2. | Ә, ә | Ä, ä | ئه |
| 3. | Б, б | B, b | ب |
| 4. | В, в* | W, w | و |
| | | V, v | ۋ |
| 5. | Г, г** | G, g | گ |
| | | Ğ, ğ | ع |
| 6. | Д, д | D, d | د |
| 7. | Е, е | E, e | ىُ |
| | Ё, ё | Yo, yo | يُو |
| 8. | Ж, ж | J, j | ژ |
| 9. | Җ, җ | C, c | ج |
| 10. | З, з | Z, z | ز |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 11. | И, и | İ, i | ئی |
| 12. | Й, й | Y, y | ي |
| 13. | К, к** | K, k | ک |
| | | Q, q | ق |
| 14. | Л, л | L, l | ل |
| 15. | М, м | M, m | م |
| 16. | Н, н | N, n | ن |
| 17. | ң | ñ | ڭ |
| 18. | О, о | O, o | ئُوِ |
| 19. | Ө, ө | Ö, ö | ئُو |
| 20. | П, п | P, p | پ |
| 21. | Р, р | R, r | ر |
| 22. | С, с | S, s | س |
| 23. | Т, т | T, t | ت |
| 24. | У, у | U, u | ئوِ |
| 25. | Ү, ү | Ü, ü | ئو |
| 26. | Ф, ф | F, f | ف |
| 27. | Х, х | X, x | ح |
| 28. | Һ, һ | H, h | ه |
| 29. | Ц, ц | Ts, ts | تس |
| 30. | Ч, ч | Ç, ç | چ |
| 31. | Ш, ш | Ş, ş | ش |
| 32. | Щ, щ | Şç, şç | شچ |
| 33. | ъ | - | - |
| 34. | Ы, ы | I, ı | یُِ |
| 35. | ь | - | - |
| 36. | Э, э | E, e | یُ |
| 37. | Ю, ю | Yu, yu | يو |
| 38. | Я, я | Ya, ya | يا |

* Татар телендә «в» хәрефе ике аваз белдерү өчен кулланыла: чын татар сүзләрендә – [w], алынма сүзләрдә [в] авазы ишетелә. Латин һәм гарәп графикаларында һәр аваз өчен аерым хәреф билгеләнгән.

** Татар телендә «к» һәм «г» хәрефләре ике аваз белдерү өчен кулланыла: йомшак [г] һәм [к] һәм калын [гъ] һәм [къ]. Латин һәм гарәп графикаларында һәр аваз өчен аерым хәреф билгеләнгән.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 2. Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 24 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Җир кодексына (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 1999, № 8 (I өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3, № 5 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 19 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасына федераль милектән түләүсез тапшырылган.»;

2) 20 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«муниципаль милеккә федераль милектән түләүсез тапшырылган.»;

3) 21 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле $5^1$ пунктча өстәргә:

«$5^1$) дәүләт яисә муниципаль милектәге җирләрдән – федераль законда каралган очракларда торак-төзелеш кооперативларына;»;

4) 31 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Әлеге гариза дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге (алга таба – күпфункцияле үзәк) аша да бирелергә мөмкин.»;

5) $32^1$ статьяда:

а) 9 пунктның икенче абзацына «бирелергә мөмкин» сүзләре алдыннан «турыдан-туры җирле үзидарәнең вәкаләтле органына йә күпфункцияле үзәк аша да» сүзләрен өстәргә;

б) 16 пунктның икенче абзацына «бирелергә мөмкин» сүзләре алдыннан «турыдан-туры җирле үзидарәнең вәкаләтле органына йә күпфункцияле үзәк аша да» сүзләрен өстәргә;

в) 18 пунктта «гаризаны алар җирле үзидарә органына биргән көннән» сүзләрен «гариза җирле үзидарә органына кергән көннән» сүзләренә алмаштырырга;

б) 44 статьяның 2 пунктындагы икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Милеккә җир кишәрлеген бирү турындагы яисә җир кишәрлеген милеккә бирүдән баш тарту турындагы карар тиешле җир кишәрлекләрен бирү хокукына ия булган башкарма хакимиятнең вәкаләтле органына яисә җирле үзидарә органына арендатор тарафыннан язма рәвештә яисә, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып, электрон документ рәвешендә гариза бирелгән көннән соң 30 көн эчендә кабул ителергә тиеш. Әлеге гариза күпфункцияле үзәк аша да бирелергә мөмкин.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 елның 12 гыйнвары
№ 2-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 3. Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 2.2 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 24 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 2.2 статьясын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 9 – 10, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 3, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 10 (II өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2012, № 1; Ва-

таным Татарстан, 2012, 20 июнь, 24 июль) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2 статья. **Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатының, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутатының, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасының законлы таләпләрен үтәмәү**

Татарстан Республикасы дәүләт органының, җирле үзидарә органының, Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет акчалары исәбеннән тулысынча яисә өлешчә финанслана торган йә гамәлгә куючылары Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм (яисә) җирле үзидарә органнары булган оешманың, иҗтимагый берләшмәнең вазыйфаи затлары Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатының законлы таләпләрен үтәмәгән йә аның эшчәнлеген гамәлгә ашыруга каршылык тудырган өчен –

ике меңнән өч мең сумга кадәр күләмдә административ штраф салына.

Әлеге статьяның беренче өлешендә күрсәтелгән вазыйфаи затлар Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатына, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына мәгълүмат (документлар, материаллар, мөрәҗәгатьләргә җаваплар) бирүнең билгеләнгән срокларын үтәмәгән, шулай ук аларга күрәләтә ялган мәгълүмат биргән өчен –

бер меңнән ике мең сумга кадәр күләмдә административ штраф салына.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 елның 12 гыйнвары
№ 3-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 4. «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законының 30 һәм 38 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында»

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 24 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 4 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш); 2012, № 3) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 30 статьяның 5 пунктында «дәүләт экспертизасының» сүзләрен «экспертизаның» сүзенә алмаштырырга;

2) 38 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Мәдәни мирас объектын саклап калу буенча эшләр башкаруга рөхсәт һәм йөкләмә алу өчен кирәкле документлар кабул итү һәм мәдәни мирас объектын саклап калу буенча эшләр башкаруга рөхсәт һәм йөкләмә бирү дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша гамәлгә ашырылырга мөмкин.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 елның 12 гыйнвары
№ 4-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 5. «Латин графикасы нигезендә татар алфавитын торгызу турында» Татарстан Республикасы Законының үз көчен югалтуын тану хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 24 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Латин графикасы нигезендә татар алфавитын торгызу турында» 1999 елның 15 сентябрендәге 2352 номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1999, № 10) үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 елның 12 гыйнвары
№ 5-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 6. Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 24 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Экология кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 1) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 1 өлешендә:

а) унынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«дәүләт экология мониторингы (әйләнә-тирә мохитнең дәүләт мониторингы) – әйләнә-тирә мохитнең, шул исәптән

табигать мохите компонентларының, табигый экологик системаларның торышына, аларда бара торган процессларга, күренешләргә комплекслы күзәтү, әйләнә-тирә мохит торышындагы үзгәрешләрне бәяләү һәм фаразлау;»;

б) утызынчы абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

2) 3 статьяның сигезенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«дәүләт экология күзәтчелегенең бәйсезлеге;»;

3) 8 статьяның 1 өлешендә:

а) бишенче абзацта «әйләнә-тирә мохитнең дәүләт мониторингын (дәүләт экология мониторингын)» сүзләрен «экология мониторингын (әйләнә-тирә мохитнең дәүләт мониторингын)» сүзләренә алмаштырырга, «күзәтүнең» сүзеннән соң «дәүләт экология мониторингының (әйләнә-тирә мохитнең дәүләт мониторингының) бердәм системасы өлешен тәшкил итүче» сүзләрен өстәргә;

б) ундүртенче абзацта «экология контролендә» сүзләрен «экология күзәтчелегендә» сүзләренә алмаштырырга;

в) егерме дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«федераль дәүләт урман күзәтчелеген (урманны саклауны) гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның исемлеген һәм урманнарда федераль дәүләт янгын күзәтчелеген гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның исемлеген билгеләү;»;

4) 34 статьяның 3 пунктында «2001 елның 8 августындагы 128-ФЗ номерлы» сүзләрен «2011 елның 4 маендагы 99-ФЗ номерлы» сүзләренә алмаштырырга, «җыю, куллану,», «транспортировкалау,» сүзләрен төшереп калдырырга;

5) VIII кисәкнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«VIII КИСӘК
**ДӘҮЛӘТ ЭКОЛОГИЯ МОНИТОРИНГЫ (ӘЙЛӘНӘ-ТИРӘ МОХИТНЕҢ ДӘҮЛӘТ МОНИТОРИНГЫ)**»;

6) 50 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«50 статья. **Дәүләт экология мониторингын (әйләнә-тирә мохитнең дәүләт мониторингын) гамәлгә ашыру**

1. Дәүләт экология мониторингын (әйләнә-тирә мохитнең дәүләт мониторингын) гамәлгә ашыру дәүләт экология мониторингының (әйләнә-тирә мохитнең дәүләт мониторингының) бердәм системасы кысаларында дәүләт экология мониторингының (әйләнә-тирә мохитнең дәүләт мониторингының) бердәм

системасының ярдәмче системалары кысаларында күзәтчелек челтәрләрен һәм мәгълүмат ресурсларын булдыру һәм аларның эшчәнлеген тәэмин итү, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан дәүләт экология мониторингы (әйләнә-тирә мохитнең дәүләт мониторингы) күрсәткечләренең дәүләт фондын төзү һәм аннан файдалану ярдәмендә федераль башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан аларның Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән компетенцияләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Дәүләт экология мониторингын (әйләнә-тирә мохитнең дәүләт мониторингын) гамәлгә ашыруда катнашучы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тиешле мониторингны гамәлгә ашыру барышында алына торган мәгълүматны дәүләт экология мониторингы (әйләнә-тирә мохитнең дәүләт мониторингы) күрсәткечләренең дәүләт фондына җибәрергә тиеш.»;

7) 51 – 59 статьяларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

8) $135^2$ статьяның 2 өлешендә «әйләнә-тирә мохитне дәүләт тарафыннан мониторинглау» сүзләрен «дәүләт экология мониторингының (әйләнә-тирә мохитнең дәүләт мониторингының)» сүзләренә алмаштырырга;

9) 144 статьяда:

а) исемендә «һәм контроль» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 1 өлештә «һәм контроль» сүзләрен төшереп калдырырга, «гамәлгә ашырыла» сүзләре татарча текстта үзгәрешсез кала;

в) 2 өлештә «һәм контроль» сүзләрен төшереп калдырырга, «гамәлгә ашырыла» сүзләре татарча текстта үзгәрешсез кала;

10) 164 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«164 статья. **Җитештерү һәм куллану калдыкларын зарарсызландыру һәм урнаштыру эшчәнлеген лицензияләү**

Җитештерү һәм куллану калдыкларын зарарсызландыру һәм урнаштыру эшчәнлеген лицензияләү «Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында» 2011 елның 4 маендагы 99-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 елның 12 гыйнвары
№ 6-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 7. «Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистры турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 4 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 24 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистры турында» 2009 елның 9 февралендәге 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 2; 2011, № 12 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 2 өлешендә:

а) икенче абзацта «һәм документаль рәвештә (кәгазь саклагычларда)» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Электрон рәвештәге муниципаль норматив хокукый актның кәгазь саклагычтагы акт эчтәлегенә туры килүен билгеләү максатларында вәкаләтле орган таләбе буенча соратып алына торган акт тиешле җирле үзидарә органы мөһере һәм вәкаләтле вазыйфаи зат имзасы белән таныкланган рәсми күчермәсе рәвешендә тапшырыла.»;

2) 4 статьяның 1 өлешендә:

а) икенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

б) өченче абзацта «Электрон рәвештәге муниципаль норматив хокукый актлар» сүзләрен «Муниципаль норматив хокукый актлар электрон рәвештә» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 елның 12 гыйнвары
№ 7-ТРЗ

## 8. Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 24 декабрендә
кабул ителде

Әлеге Закон «Ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга социаль ярдәм буенча өстәмә гарантияләр турында» 1996 елның 21 декабрендәге 159-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон) нигезендә ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар арасыннан һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларга (алга таба шулай ук – ятим балалар, ятим бала) махсуслаштырылган торак фондыннан махсуслаштырылган торак урыннарын яллау шартнамәләре буенча торак урыннары бирү тәртибен билгели.

1 статья. **Гомуми нигезләмәләр**

1. Федераль законның 8 статьясындагы 1 пункты нигезендә түбәндәгеләр махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннары белән тәэмин ителергә тиеш:

1) социаль яллау шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучылар яисә социаль яллау шартнамәсе буенча торак урынын яллаучының гаилә әгъзалары булмаган йә торак урыннары милекчеләре булмаган ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар арасыннан һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затлар;

2) социаль яллау шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучылар яисә социаль яллау шартнамәсе буенча торак урынын яллаучының гаилә әгъзалары булган йә торак урыннары милекчеләре булган ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар арасыннан һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затлар,

моңа кадәр биләп тора торган торак урыннарында алар өчен яшәү мөмкинлеге булмавы әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә танылган очракта.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән гражданнар аларның яшәү урыны буенча, ә даими яшәү урынын ачыклау мөмкин булмаган очракта, күрсәтелгән затлар мәгариф учреждениеләрендә, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен законнарда билгеләнгән тәртиптә төзелә торган халыкка социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрендә тора торган урыны буенча бер мәртәбә махсуслаштырылган торак фондыннан Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы (алга таба – вәкаләтле орган) тарафыннан торак урыннары белән тәэмин ителергә тиеш.

3. Ятим балаларга торак урыны бирү вакытына тиешле торак пункт чигендә аларның яшәү урыны буенча махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннары булмаган очракта, күрсәтелгән затларга аларның ризалыгы белән махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннары Татарстан Республикасы чикләрендә башка торак пунктта бирелә.

4. Социаль яллау шартнамәләре буенча яллаучылары һәм яллаучыларның гаилә әгъзалары йә милекчеләре булган ятим балалар моңа кадәр биләп тора торган торак урыннарында Федераль законда билгеләнгән шартлар булганда, шулай ук мондый торак урыннарында түбәндәге затлар яши торган очракларда ятим балалар өчен яшәү мөмкинлеге юк дип таныла:

1) торак урыныннан мөстәкыйль файдалану хокукы булган шушы ятим балаларның гаилә әгъзалары булмаган затлар;

2) уллыкка алу юкка чыгарылган булса, шушы ятим балаларның элеккеге уллыкка алучылары булган затлар;

3) законнарда билгеләнгән тәртиптә хокуктан файдалануга сәләтсез яисә хокуктан файдалану сәләте чикләнгән дип танылган затлар;

4) хөкем ителүе булган яисә элек хөкем ителгән йә кеше гомеренә һәм сәламәтлегенә, җенси кагылгысызлыкка һәм шәхеснең җенси ирегенә каршы, гаиләгә һәм балигъ булмаганнарга каршы, халык сәламәтлегенә һәм иҗтимагый әхлаклылыкка, шулай ук иҗтимагый иминлеккә каршы җинаятьләр кылган өчен җинаять эзәрлекләвенә дучар булган яисә элек дучар ителгән затлар (үзләренә карата реабилитацияләү нигезләре буенча җинаять эзәрлекләве туктатылган затлардан тыш);

5) хроник алкоголизм, наркомания белән һәм психик авырулар белән авыручы һәм тиешле сәламәтлек саклау учреждениеләрендә исәптә торучы затлар.

2 статья. **Махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыны алу хокукына ия ятим балалар исемлеген төзү тәртибе**

1. Ятим балаларның законлы вәкилләре махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыны алу хокукына ия булган ятим балалар исемлегенә (алга таба – исемлек) ятим балаларны кертү турындагы гаризаларны вәкаләтле органга турыдан-туры үзләре йә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәк аша, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең төбәк порталыннан файдаланып, электрон рәвештә яисә кәгазьдә язылган килеш, ятим балаларга 14 яшь тулган көннән яисә ятим балаларга 14 яшь тулганнан соң аларга торак урыннары бирү өчен Федераль законда һәм әлеге Законда каралган нигезләр барлыкка килгән көннән башлап 30 көннән дә соңга калмыйча тапшыралар.

2. Исемлеккә кертү турындагы гаризаларны вәкаләтле органга шулай ук түбәндәгеләр дә тапшырырга мөмкин:

1) тулысынча хезмәткә сәләтле (эмансипацияләнгән) дип игълан ителгән ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, әгәр алар тулысынча хезмәткә сәләтле дип танылганчы әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә исемлеккә кертелмәгән булсалар, – балигъ яшькә җиткәнче;

2) ятим балалар арасыннан һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затлар, әгәр алар 18 яшькә кадәр әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә исемлеккә кертелмәгән булсалар яисә үзләренең торак урыннары белән тәэмин ителү хокукын 2013 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлгә ашырмаган булсалар.

3. Исемлеккә кертү турындагы гаризага ятим баланың паспортының яисә аның шәхесен таныклый торган башка документының күчермәсе, законлы вәкиленең шәхесен һәм аның вәкаләтләрен таныклый торган документ йә ятим баланы тулысынча хезмәткә сәләтле (эмансипацияләнгән) дип игълан итүне таныклый торган документ, шулай ук ятим бала, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган бала статусын раслый торган документлар өстәлеп бирелә.

4. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән категориягә керә торган ятим балага карата документлар тапшырганда өстәмә рәвештә күчемсез милеккә һәм аның белән алыш-бирешләргә хокукларны дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыручы органның Россия Федерациясе территориясендә ятим баланың милекчелек хокукында торак урыннары булуы яисә булмавы турында белешмәсе, шулай ук гариза бирелгән вакытка ятим баланың яшәү урыны буенча яисә тору урыны буенча теркәлүен раслый торган документ кушылып бирелә.

5. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 өлешенең 2 пунктында күрсәтелгән категориягә керә торган ятим балага карата документлар тапшырганда өстәмә рәвештә ул били торган торак урынында яшәү мөмкинлеге булмауның Федераль законда һәм әлеге Законда билгеләнгән шартларын, әлеге Законның 1 статьясындагы 4 өлешенең 4 һәм 5 пунктларында күрсәтелгән шартлардан тыш, раслый торган документлар кушылып бирелә. Әлеге Законның 1 статьясындагы 4 өлешенең 4 һәм 5 пунктларында күрсәтелгән шартларны раслау өчен кирәкле документлар вәкаләтле орган тарафыннан мөстәкыйль рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында соратып алына.

6. Дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар, дәүләтнең башка органнары, җирле үзидарә органнары йә дәүләт органнары яисә җирле үзидарә органнарына караган һәм дәүләт, муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы оешмалар эш итүендә булган документлар гражданнар тарафыннан тапшырылмаган очракта, күрсәтелгән документлар законнарда билгеләнгән тәртиптә вәкаләтле орган тарафыннан соратып алына.

7. Документлар тапшырганда мөрәҗәгать итүчегә, аларның исемлеген һәм аларны алу датасын күрсәтеп, шулай ук ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында соратып алыначак документларның исемлеген күрсәтеп, шушы документларның алынуына расписка бирелә.

8. Вәкаләтле орган ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тапшырылган һәм (яисә) алынган документларны тикшерү эшен оештыра һәм тапшыру бурычы мөрәҗәгать итүчегә йөкләнгән документлар тапшырылган көннән башлап 30 көннән дә соңга калмыйча шушы органга әлеге Законның 1 статьясындагы 1 өлешенең 2 пунктында күрсәтелгән категориягә керә торган ятим балаларның моңа кадәр биләп тора торган торак урыннарында яшәү мөмкинлеге булу йә булмау турындагы

бәяләмә бирә һәм аларны исемлеккә кертү йә кертүдән баш тарту турында карар кабул итә.

9. Исемлеккә кертүдән баш тарту турындагы карар вәкаләтле орган тарафыннан түбәндәге очракта кабул ителә, әгәр:

1) ятим бала әлеге Законның 1 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән гражданнар категорияләренең берсенә дә кермәсә;

2) тапшыру бурычы мөрәҗәгать итүчегә йөкләнгән документлар тапшырылмаган яисә тулы күләмдә тапшырылмаган булса;

3) тиешле документ мөрәҗәгать итүченең үз инициативасы белән тапшырылмаган булса, дәүләт хакимияте органының, җирле үзидарә органының йә дәүләт хакимияте органына яисә җирле үзидарә органына караган оешманың ведомствоара гарызнамәгә җавабында соратып алына торган документның һәм (яисә) мәгълүматның булмавы таныкланса, моңа соратып алына торган мондый документның яисә мәгълүматның шушы органнар яисә оешмалар эш итүендә булмавы тиешле гражданнарның исемлеккә кертелү хокукын раслый торган очраклары керми;

4) тапшырылган документларда ятим бала турында дөрес булмаган белешмәләр булса.

10. Ятим баланы исемлеккә кертүдән баш тарту, исемлеккә кертүдән баш тарту өчен нигез булып хезмәт итүче шартларны бетергәннән соң, аны исемлеккә кертү турындагы гариза белән вәкаләтле органга кабат мөрәҗәгать итү өчен тоткарлык була алмый.

11. Вәкаләтле орган ятим баланы исемлеккә кертү йә исемлеккә кертүдән баш тарту турында карар кабул иткән көннән башлап өч эш көненнән дә соңга калмыйча тиешле документларны тапшырган гражданга ятим баланы исемлеккә кертү йә исемлеккә кертүдән баш тарту турында карар кабул итүне раслый торган документ, аңа моңа кадәр билләп тора торган торак урыннарында яшәү мөмкинлеге булу йә булмау турындагы бәяләмәне өстәп, җибәрә.

12. Ятим балаларны исемлеккә кертү йә исемлеккә кертүдән баш тарту турындагы карарга һәм моңа кадәр билләп тора торган торак урыннарында яшәү мөмкинлеге булу йә булмау турындагы бәяләмәгә карата законнарда билгеләнгән тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.

3 статья. **Ятим балаларга торак урыннары бирү тәртибе**

1. Торак урыннары әлеге Законның 1 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән гражданнарга 18 яшькә җиткәндә, шулай

ук балигъ булганчы тулысынча хокукка сәләт алган очракта йә әлеге затларның мәгариф учреждениеләрендә, халыкка социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрендә булу срогы алар 18 яшькә җиткәнче тәмамланганда бирелә.

2. Ятим бала 18 яшькә җитәргә йә аның мәгариф учреждениесендә, халыкка социаль хезмәт күрсәтү учреждениесендә булу срогы тәмамланырга бер ел калгач, законлы вәкил ятим баланы торак урыны белән тәэмин итү турындагы үтенечнамә белән вәкаләтле органга мөрәҗәгать итә. Элек тапшырылган документлардагы белешмәләр үзгәртелгәндә, законлы вәкил әлеге белешмәләрне үзгәртүләр турында үтенечнамәдә хәбәр итә.

3. Бирелгән үтенечнамәләр нигезендә вәкаләтле орган махсуслаштырылган торак фондының торак урыннарын алучы ятим балалар реестрын төзи, ятим баланы реестрга кертү турында законлы вәкилләргә 10 көн эчендә хәбәр ителә.

4. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән хәлләр барлыкка килгән көннән 30 көн эчендә ятим балалар махсуслаштырылган торак урынын яллау шартнамәсе буенча торак урыны бирелү турында вәкаләтле органга гариза бирә.

5. Гариза биргән көннән 15 көннән дә соңга калмыйча вәкаләтле орган торак урыны бирү турында карар кабул итә һәм махсуслаштырылган торак урынын яллау шартнамәсен биш ел срокка төзи.

6. Торак урыны бирү мизгеленә әлеге Законның 1 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән таләпләргә туры килми торган ятим балалар махсуслаштырылган торак фондының торак урыннарын алучы ятим балалар реестрыннан төшереп калдырылырга тиеш, бу хакта аларга вәкаләтле орган 10 көн эчендә хәбәр итә.

7. Ятим балалар өчен махсуслаштырылган торак урынын яллау шартнамәләре буенча торак урыннары биләүче ятим балалар тарафыннан торак урыннары һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү социаль яллау шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучылар өчен билгеләнгән тарифлар буенча башкарыла.

8. Махсуслаштырылган торак урынын яллау шартнамәсе буенча торак урыннарын биләүче һәм «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә аз керемлеләр дип танылган

ятим балалар торак урынынннан файдаланган өчен түләү (яллау өчен түләү) кертүдән азат ителә.

9. Ятим балалар өчен махсуслаштырылган торак фондында бушаган торак урыннары булмаган очракта, вәкаләтле орган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда ятим балаларның уңайлы торак урыннарында вакытлыча яшәвен тәэмин итә.

10. Махсуслаштырылган торак урынын яллау шартнамәсе өзелгәндә яисә туктатып торылганда, социаль яллау шартнамәсе төзелү очракларыннан гайре, торак урыны әлеге Закон нигезендә торак урыны белән тәэмин ителүгә мохтаҗ бүтән затка бирелә.

4 статья. **Ятим балалар өчен торак урыннарының саклануын тәэмин итү**

1. Вәкаләтле орган Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең бүтән кызыксынучы органнары белән хезмәттәшлектә билгеләнгән компетенция кысаларында социаль яллау шартнамәләре буенча яллаучылары яисә яллаучыларның гаилә әгъзалары йә милекчеләре ятим балалар булган, бирелгән торак урыннарыннан файдалануны һәм (яисә) эш итүне, шушы торак урыннарының тиешле санитария хәлен һәм техник торышын тәэмин итүне түбәндәге максатларда тикшереп тора:

1) торак урынын алмаштыру яисә читләштерү буенча законсыз алыш-биреш килешүләре башкаруны булдырмый калу;

2) торак урынында шуңа законлы нигезләре булмаган затларның яшәвен булдырмый калу;

3) торак урынын билгеләнеше буенча файдалануны тәэмин итү, тиешле халәттә тоту;

4) санитар-техник һәм бүтән төрле җайланмаларның саклануын тәэмин итү;

5) янгын куркынычсызлыгы таләпләрен, санитария-гигиена һәм экологик таләпләрне үтәү;

6) торак урынында аны бозуга китерерлек эшләр яисә башка гамәлләр башкаруны булдырмый калу;

7) торак урынын билгеләнгән тәртипне бозып үзгәртеп коруны һәм (яисә) яңадан планлаштыруны булдырмый калу.

2. Вәкаләтле орган, торак урыннарының саклануын һәм алардан файдалануны бозулар ачыкланганда, торак урынын карап чыгу актын төзи һәм аларны бетерү буенча кичекмәстән чаралар күрә.

5 статья. **Махсуслаштырылган торак урынын яллау шартнамәсен яңа срокка төзү яисә бирелгән торак урынына карата социаль яллау шартнамәсен төзү тәртибе**

1. Вәкаләтле орган махсуслаштырылган торак урынын яллау шартнамәсенең гамәлдә булу срогы тәмамланганга кадәр өч ай алдан әлеге шартнамә буенча яллаучының тормыш шартларын тикшерә, авыр тормыш хәлләрен җиңеп чыгуда ятим балаларга ярдәм итү зарурлыгын таныклый торган хәлләрнең булуын йә булмавын билгеләү максатларында кирәкле белешмәләрне һәм документларны (яллаучының тормыш шартларын карап чыгу актларын, гаилә составы һәм торак урынында теркәлгән затлар турында, яллаучының керемнәре турында, яллаучының, аның гаилә әгъзаларының авыруы, инвалидлыгы булу-булмау турында яшәү урыныннан документларны, яллаучыга карата хокук саклау органнарының чыгарылган актларын, яллаучының җәза үтәвен (булган очракта) раслый торган документларны) соратып ала.

2. Тикшерү нәтиҗәләре буенча вәкаләтле орган авыр тормыш хәлләрен җиңеп чыгуда ятим балаларга ярдәм итү зарурлыгын таныклый торган хәлләр булу йә булмау турында бәяләмә чыгара.

3. Вәкаләтле органның бәяләмәсендә махсуслаштырылган торак урынын яллау шартнамәсен яңа срокка төзүнең яисә яллаучы били торган торак урынын социаль яллау шартнамәсен төзүнең нигезлелеге хакындагы нәтиҗә булырга тиеш.

4. Махсуслаштырылган торак урынын яллау шартнамәсенең гамәлдә булу срогы тәмамланырга 30 көн кала вәкаләтле орган авыр тормыш хәлләрен җиңеп чыгуда ятим балаларга ярдәм итү зарурлыгын раслый торган хәлләр булу турындагы бәяләмә нигезендә махсуслаштырылган торак урынын яллау шартнамәсен яңа срокка бер мәртәбә төзү турында карар кабул итә, бу хакта карар кабул ителгән көннән 10 көн эчендә ятим балага хәбәр ителә.

5. Авыр тормыш хәлләрен җиңеп чыгуда ятим балаларга ярдәм итү зарурлыгын раслый торган хәлләр булмау турындагы бәяләмә нигезендә вәкаләтле орган махсуслаштырылган торак урынын яллау шартнамәсенең гамәлдә булу срогы тәмамланырга 30 көннән дә соңга калмыйча махсуслаштырылган торак урынын яллау шартнамәсен өзү һәм шушы торак урынын социаль яллау шартнамәсе төзү турында карар кабул итә, бу хакта карар кабул ителгән көннән 10 көн эчендә ятим балага хәбәр ителә.

6. Әлеге статьяның 4 һәм 5 өлешләрендә күрсәтелгән карарларга карата суд тәртибендә шикаять белдерелергә мөмкин.

7. Вәкаләтле орган карар кабул ителгән көннән 30 көннән дә соңга калмыйча махсуслаштырылган торак урынын яллау шартнамәсен өзә һәм әлеге торак урынын социаль яллау шартнамәсен төзи йә махсуслаштырылган торак урынын яллау шартнамәсен биш еллык яңа срокка төзи.

6 статья. **«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында**

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш), № 12 (III өлеш); 2005, № 2; 2006, № 2 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 5 (I өлеш), №12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш); Ватаным Татарстан, 2012, 19 июнь, 25 июль), 5 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«5. Социаль яллау шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучы яисә социаль яллау шартнамәсе буенча торак урынын яллаучының гаилә әгъзалары булмаган йә торак урыннары милекчеләре булмаган ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затлар, шулай ук социаль яллау шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучы яисә социаль яллау шартнамәсе буенча торак урыннарын яллаучының гаилә әгъзалары булган йә торак урыннары милекчеләре булган ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затлар, әгәр аларның элек били торган торак урыннарында яшәүләре мөмкин түгел дип танылса, махсуслаштырылган торак фондының торак урыннары белән махсуслаштырылган торак урыннарын яллау шартнамәләре буенча Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә тәэмин ителергә тиеш.

Ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга мөлкәткә һәм торак урынына хокукларның өстәмә гарантияләре Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.».

7 статья. **Йомгаклау нигезләмәләре**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Әлеге Законның гамәли көче, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затлар үзләренең торак урыннары белән тәэмин ителү хокукын 2013 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлгә ашырмаган очракта, «Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү өлешендә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2012 елның 29 февралендәге 15-ФЗ номерлы Федераль закон үз көченә кергән көнгә кадәр барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты әлеге Закон үз көченә кергән көннән 30 көн эчендә әлеге Законны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган норматив хокукый актлар кабул итәргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 елның 12 гыйнвары
№ 8-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 9. Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2013 елның язгы сессиясе секретариаты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2013 елның язгы сессиясе секретариатын түбәндәге Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары составында сайларга:

Секретариат җитәкчесе:

Зарипов Марат Хәй улы

Секретариат әгъзалары:

Гайнуллов Мөнир Әнвәр улы
Ганибаев Рифат Шаһит улы

Иванов Леонид Иванович
Каһарманов Марат Шәһәт улы.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 31 гыйнвары
№ 2644-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 10. Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2013 елның язгы сессиясе регламент төркеме турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2013 елның язгы сессиясе регламент төркемен түбәндәге Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары составында сайларга:

Төркем җитәкчесе:

Рыбушкин Николай Николаевич

Төркем әгъзалары:

Зыятдинов Азат Шәймулла улы
Садыйков Марат Наил улы.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 31 гыйнвары
№ 2645-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 11. Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2013 елның язгы сессиясе электрон системадан файдаланып тавыш бирүне тикшереп тору комиссиясе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2013 елның язгы сессиясе электрон системадан файдаланып тавыш бирүне тикшереп тору комиссиясен түбәндәге Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары составында сайларга:

Комиссия җитәкчесе:

Логинов Василий Платонович

Комиссия әгъзалары:

Барышев Леонид Анатольевич
Кәримуллин Дамир Җәүдәт улы.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 31 гыйнвары
№ 2646-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 12. Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2013 елның язгы сессиясе редакция комиссиясе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2013 елның язгы сессиясе редакция комиссиясен түбәндәге Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары составында сайларга:

Редакция комиссиясе җитәкчесе:

Ганиев Илшат Газим улы

Редакция комиссиясе әгъзалары:

Габделхаков Рөстәм Рифгать улы
Вәлиев Наил Мансур улы
Нуретдинов Рафаил Фәттах улы
Симаков Андрей Анатольевич.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 31 гыйнвары
№ 2647-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 13. Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз җиденче утырышы көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утыз җиденче утырышының түбәндәге көн тәртибен расларга:

1. Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкилләрен вазыйфаларына билгеләп кую турында.

2. «Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында» 457-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

3. «2013 елга, 2014 һәм 2015 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 454-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

4. «Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредитлары бирү турындагы килешүләргә өстәмә

килешүләрне раслау хакында» 455-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

5. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 1428-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (III укылыш).

6. «Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2391-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (III укылыш).

7 «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 2435-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).

8. «Яшьләр һәм Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәте турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 6419-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).

9. Муниципаль хезмәт турында 1448-4 номерлы Татарстан Республикасы кодексы проекты хакында (I укылыш).

10. «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең уңдырышлылыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 16 статьясына үзгәреш кертү хакында» 453-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

11. «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 456-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

12. 2012 елда Татарстан Республикасы Хисап палатасы эше турында хисап.

13. Россия Федерациясе Конституция Судына Россия Федерациясе Граждан процессуаль кодексының 26 статьясындагы беренче өлешенең 2 пункты, 251 статьясындагы беренче, икенче һәм дүртенче өлешләре, 253 статьясындагы икенче һәм өченче өлешләре нигезләмәләренең конституциячеллеген тикшерү турында гарызнамәне кире алу хакында.

14. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 14.43 статьясына үзгәреш кертү хакында” федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында.

15. «Вөҗдан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 343 статьясына үзгәрешләр кертү хакында»

195229-6 номерлы федераль закон проекты турында (руханилар, дини персонал һәм дини оешмалар хезмәткәрләренә, шулай ук күрсәтелгән вазыйфаларга кандидатлар өчен таләпләр билгеләү хокукын дини оешмаларга бирү өлешендә).

16. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 5.63 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 168733-6 номерлы федераль закон проекты турында (административ хокук бозулар составларын төгәлләштерү өлешендә).

17. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 181965-6 номерлы федераль закон проекты турында (юл хәрәкәте өлкәсендә хокук бозуларны кабат кылган өчен җаваплылыкны көчәйтү турында).

18. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 200753-6 номерлы федераль закон проекты хакында (Россия Федерациясендә торак урыннарында затларны фиктив теркәү өчен алшартларны бетерү максатларында һәм торган урында яисә яшәгән урында Россия гражданнарын теркәү кагыйдәләрен бозган өчен һәм аларның Россия Федерациясендә торак урыннарында теркәлмичә яшәгәннәре өчен административ җаваплылык билгеләү турында, шулай ук Россия гражданнарын торган урында яисә яшәгән урында Россия Федерациясендә фиктив теркәгән өчен һәм Россия Федерациясендә чит ил гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган затларны торак урыннарында миграция исәбенә фиктив алган өчен җинаять җаваплылыгын билгеләү турында).

19. «Россия Федерациясе Җинаять кодексының 169 һәм $171^1$ статьяларына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Башкортостан Республикасы Дәүләт Җыелышы – Корылтаеның закон чыгару инициативасы хакында.

20. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 20.25 һәм 28.3 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Алтай Республикасы Дәүләт Җыелышы – Эл Корылтаеның закон чыгару инициативасы турында.

21. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Ставрополь крае Думасының закон чыгару инициативасы турында.

22. «Россия Федерациясе Граждан кодексының өченче өлешендәге 1151 статьясына үзгәреш кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Удмурт Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы хакында.

23. «Электрон имза турында» Федераль законга үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Пермь крае Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында.

24. «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль законның 21 статьясына үзгәреш кертү хакында» 182753-6 номерлы федераль закон проекты турында (инвалидларны эшкә урнаштыру өчен квота бирелгән эш урыннары санын исәпләгәндә оешма хезмәткәрләренең санын авыр эшләр, зарарлы һәм (яисә) хәвефле һәм башка аерым хезмәт шартлары булган эшләр башкару белән шөгыльләнүче хезмәткәрләр санына кимәтү өлешендә).

25. Хезмәткә сәләтсез гражданнарны караучы эшләмәүче затларга компенсация түләүләрен җайга салучы гамәлдәге норматив актларны үзгәртү мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министры М.А. Топилинга Оренбург өлкәсе Закон чыгару Собраниесе депутатлары мөрәҗәгате турында.

26. «Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләрнең финанс ягын хәл итү турында» Федераль законның 20.1 статьясына үзгәреш кертү хакында» 185943-6 номерлы федераль закон проекты турында.

27. «Россия Федерациясе Җир кодексының 28 статьясына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Карелия Республикасы Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы хакында.

28. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 177474-6 номерлы федераль закон проекты турында (даими рәвештә пассажирлар йөртү өлкәсендә муниципаль контроль турында).

29. «Россия Федерациясендә чит ил гражданнарының хокукый хәле турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 184699-6 номерлы федераль закон проекты турында (Россия

Федерациясендә чит ил гражданы яисә гражданлыгы булмаган зат белән хезмәт шартнамәсен төзү рөхсәт ителгән яшь критерие буларак 18 яшьне билгеләү турында, шулай ук чит ил гражданына яисә гражданлыгы булмаган затка Россия Федерациясендә эшләүгә рөхсәт бирүдән яисә физик затларда хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыру хокукына патент бирүдән баш тарту йә аларда булган рөхсәтне яисә патентны юкка чыгару өчен өстәмә нигез буларак чит ил хезмәткәренең 18 яшькә җитмәвен күрсәтүне билгеләү хакында).

30. «Рәсми спорт ярышлары нәтиҗәләренә хокукый каршылыклы йогынтыны булдырмау максатларында «Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 200769-6 номерлы федераль закон проекты турында.

31. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 176205-6 номерлы федераль закон проекты турында (муниципаль контрольне гамәлгә ашыру өлкәсендә закон таләпләрен бозган өчен административ җаваплылык билгеләү хакында).

32. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 12.15 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 187796-6 номерлы федераль закон проекты турында (транспорт чарасының транспорт юлы өлешендә урнашуы, каршыга килгәндә юл бирешү яисә узып китү кагыйдәләрен бозган өчен җаваплылыкны көчәйтү турында).

33. Төрлесеннән.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 31 гыйнвары
№ 2648-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 14. Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкилләре турында

«Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкилләре турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкилләре вазыйфаларына түбәндәгеләрне билгеләп куярга:

Абдуллин Гадел Илсөяр улын;
Антонов Игорь Олеговичны;
Әхмәтова Рәзинә Гайзулла кызын;
Гомәров Ленар Әсхәт улын;
Кулешов Евгений Александровичны;
Кучин Виктор Антоновичны;
Садовский Ростислав Игоревичны.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 31 гыйнвары
№ 2649-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 15. «Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында» 457-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турын-

да беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында» 457-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 31 гыйнвары
№ 2650-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 16. «Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы хакында (457-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын (457-4 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 31 гыйнвары
№ 2651-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 17. «2013 елга, 2014 һәм 2015 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 454-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан кертелгән «2013 елга, 2014 һәм 2015 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 454-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 31 гыйнвары
№ 2652-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 18. «2013 елга, 2014 һәм 2015 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (454-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «2013 елга, 2014 һәм 2015 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (454-4 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 31 гыйнвары
№ 2653-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 19. «Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредитлары бирү турындагы килешүләргә өстәмә килешүләрне раслау хакында» 455-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан кертелгән «Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредитлары бирү турындагы килешүләргә өстәмә килешүләрне раслау хакында» 455-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 31 гыйнвары
№ 2654-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 20. «Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредитлары бирү турындагы килешүләргә өстәмә килешүләрне раслау хакында» Татарстан Республикасы законы турында (455-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредитлары бирү турындагы килешүләргә өстәмә килешүләрне раслау хакында» Татарстан Республикасы законын (455-4 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 31 гыйнвары
№ 2655-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 21. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы хакында (1428-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын (1428-4 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 31 гыйнвары
№ 2656-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 22. «Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (2391-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (2391-4 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 31 гыйнвары
№ 2657-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 23. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 2435-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 2435-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 31 гыйнвары
№ 2658-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 24. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (2435-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (2435-4 номерлы проект) кабул итәргә.
2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 31 гыйнвары
№ 2659-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 25. «Яшьләр һәм Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәте турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 6419-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Яшьләр һәм Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәте турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 6419-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты күрсәтелгән закон проектын эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына өченче укылышта карауга кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 31 гыйнвары
№ 2660-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 26. Муниципаль хезмәт турында 1448-4 номерлы Татарстан Республикасы кодексы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары В.Н. Липужина, Н.К. Хөснетдинов тарафыннан кертелгән Муниципаль хезмәт турында 1448-4 номерлы Татарстан Республикасы кодексы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән кодекс проектына төзәтмәләр 2013 елның 28 февраленә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитетына кертелә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты әлеге кодекс проектын,

кергән төзәтмәләрне исәпкә алып, 2013 елның 31 мартына кадәр эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 31 гыйнвары
№ 2661-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 27. «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең уңдырышлылыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 16 статьясына үзгәреш кертү хакында» 453-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты В.П. Васильев тарафыннан кертелгән «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең уңдырышлылыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 16 статьясына үзгәреш кертү хакында» 453-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 31 гыйнвары
№ 2662-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 28. «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең уңдырышлылыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 16 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (453-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең уңдырышлылыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 16

статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (453-4 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 31 гыйнвары
№ 2663-IV ДС

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 29. «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 456-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 456-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән закон проектына төзәтмәләр 2013 елның 15 февраленә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитетына кертелә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты әлеге закон проектын, кергән төзәтмәләрне исәпкә алып, 2013 елның 15 мартына кадәр эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 31 гыйнвары
№ 2664-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 30. 2012 елда Татарстан Республикасы Хисап палатасы эше турында хисап хакында

2012 елда Татарстан Республикасы Хисап палатасы эше турында хисапны тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. 2012 елда Татарстан Республикасы Хисап палатасы эше турында хисапны игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Хисап палатасына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

Татарстан Республикасында бюджет процессын, дәүләт мөлкәте белән идарә итү һәм аның белән эш итүнең контроль системасын алга таба да ныгыту һәм үстерү, тышкы финанс контроле стандартлары системасын формалаштыру буенча эшне дәвам итәргә;

Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты акчаларыннан файдалану нәтиҗәлелеге аудитын контроль эшчәнлектә киң куллану эшен дәвам итәргә;

бюджет кредитлары буенча Россия Федерациясе алдында Татарстан Республикасы йөкләмәләрен реструктуризацияләү буенча килешүләрнең үз вакытында үтәлешенә контрольне тәэмин итәргә;

бюджет өлкәсе учреждениеләре тарафыннан энергетика ресурсларыннан файдалануның нәтиҗәлелегенә контрольне тәэмин итәргә;

республика озак сроклы максатчан программаларының үтәлешенә контрольне тәэмин итү эшен дәвам итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 31 гыйнвары
№ 2665-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 31. Россия Федерациясе Конституция Судына Россия Федерациясе Граждан процессуаль кодексының 26 статьясындагы беренче өлешенең 2 пункты, 251 статьясындагы беренче, икенче һәм дүртенче өлешләре, 253 статьясындагы икенче һәм өченче өлешләре нигезләмәләренең конституциячеллеген тикшерү турында гарызнамәне кире алу хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

«Россия Федерациясе Конституция Суды турында» Федераль конституциячел законның 44 статьясы нигезендә Россия Федерациясе Конституция Судына Россия Федерациясе Граждан процессуаль кодексының 26 статьясындагы беренче өлешенең 2 пункты, 251 статьясындагы беренче, икенче һәм дүртенче өлешләре, 253 статьясындагы икенче һәм өченче өлешләре нигезләмәләренең конституциячеллеген тикшерү турында гарызнамәне кире алырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 31 гыйнвары
№ 2666-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 32. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 14.43 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында

Россия Федерациясе Конституциясенең 104 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 14.43 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Феде-

раль Собраниесе Дәүләт Думасына закон чыгару инициативасы тәртибендә кертергә (кушымта итеп бирелә).

2. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 14.43 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

3. Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органнарына, шулай ук Татарстан Республикасында сайланган Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларына Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасын хуплауны сорап мөрәҗәгать итәргә.

4. Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында күрсәтелгән федераль закон проектын караганда Татарстан Республикасы Дәүләт Советының рәсми вәкилләре итеп Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты Әбүбакиров Ришат Фазлетдин улын һәм Татарстан Республикасы юстиция министры Корманов Мидхәт Мәсхүт улын билгеләргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитетына йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 31 гыйнвары
№ 2667-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 33. «Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 343 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 195229-6 номерлы федераль закон проекты турында (руханилар, дини персонал һәм дини оешмалар хезмәткәрләренә, шулай ук күрсәтелгән вазыйфаларга кандидатлар өчен таләпләр билгеләү хокукын дини оешмаларга бирү өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 343 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 195229-6 номерлы федераль закон проектын (руханилар, дини персонал һәм дини оешмалар хезмәткәрләренә, шулай ук күрсәтелгән вазыйфаларга кандидатлар өчен таләпләр билгеләү хокукын дини оешмаларга бирү өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 31 гыйнвары
№ 2668-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 34. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 5.63 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 168733-6 номерлы федераль закон проекты турында (административ хокук бозулар составларын төгәлләштерү өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 5.63 статьясына үзгәрешләр кертү хакында»

168733-6 номерлы федераль закон проектын (административ хокук бозулар составларын төгәлләштерү өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 31 гыйнвары
№ 2669-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 35. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 181965-6 номерлы федераль закон проекты турында (юл хәрәкәте өлкәсендә хокук бозуларны кабат кылган өчен җаваплылыкны көчәйтү турында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 181965-6 номерлы федераль закон проектын (юл хәрәкәте өлкәсендә хокук бозуларны кабат кылган өчен җаваплылыкны көчәйтү турында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 31 гыйнвары
№ 2670-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 36. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 200753-6 номерлы федераль закон проекты хакында (Россия Федерациясендә торак урыннарында затларны фиктив теркәү өчен алшартларны бетерү максатларында һәм торган урында яисә яшәгән урында Россия гражданнарын теркәү кагыйдәләрен бозган өчен һәм аларның Россия Федерациясендә торак урыннарында теркәлмичә яшәгәннәре өчен административ җаваплылык билгеләү турында, шулай ук Россия гражданнарын торган урында яисә яшәгән урында Россия Федерациясендә фиктив теркәгән өчен һәм Россия Федерациясендә чит ил гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган затларны торак урыннарында миграция исәбенә фиктив алган өчен җинаять җаваплылыгын билгеләү турында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 200753-6 номерлы федераль закон проектын (Россия Федерациясендә торак урыннарында затларны фиктив теркәү өчен алшартларны бетерү максатларында һәм торган урында яисә яшәгән урында Россия гражданнарын теркәү кагыйдәләрен бозган өчен һәм аларның Россия Федерациясендә торак урыннарында теркәлмичә яшәгәннәре өчен административ җаваплылык билгеләү турында, шулай ук Россия гражданнарын торган урында яисә яшәгән урында Россия Федерациясендә фиктив теркәгән өчен һәм Россия Федерациясендә чит ил гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган затларны торак урыннарында миграция исәбенә фиктив алган өчен җинаять җаваплылыгын билгеләү турында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 31 гыйнвары
№ 2671-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 37. «Россия Федерациясе Җинаять кодексының 169 һәм $171^1$ статьяларына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Башкортостан Республикасы Дәүләт Җыелышы – Корылтаеның закон чыгару инициативасы хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясе Җинаять кодексының 169 һәм $171^1$ статьяларына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Башкортостан Республикасы Дәүләт Җыелышы – Корылтаеның закон чыгару инициативасын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Башкортостан Республикасы Дәүләт Җыелышы – Корылтаена җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 31 гыйнвары
№ 2672-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 38. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 20.25 һәм 28.3 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Алтай Республикасы Дәүләт Җыелышы – Эл Корылтаеның закон чыгару инициативасы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 20.25 һәм 28.3 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Алтай Республикасы Дәүләт Җыелышы – Эл Корылтаеның закон чыгару инициативасын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Алтай Республикасы Дәүләт Җыелышы – Эл Корылтаена җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 31 гыйнвары
№ 2673-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 39. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Ставрополь крае Думасының закон чыгару инициативасы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Ду-

масына кертү буенча Ставрополь крае Думасының закон чыгару инициативасын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Ставрополь крае Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 31 гыйнвары
№ 2674-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 40. «Россия Федерациясе Граждан кодексының өченче өлешендәге 1151 статьясына үзгәреш кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Удмурт Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясе Граждан кодексының өченче өлешендәге 1151 статьясына үзгәреш кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Удмурт Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Удмурт Республикасы Дәүләт Советына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 31 гыйнвары
№ 2675-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 41. «Электрон имза турында» Федераль законга үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Пермь крае Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Электрон имза турында» Федераль законга үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Пермь крае Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Пермь крае Закон чыгару Собраниесенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 31 гыйнвары
№ 2676-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 42. «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль законның 21 статьясына үзгәреш кертү хакында» 182753-6 номерлы федераль закон проекты турында (инвалидларны эшкә урнаштыру өчен квота бирелгән эш урыннары санын исәпләгәндә оешма хезмәткәрләренең санын авыр эшләр, зарарлы һәм (яисә) хәвефле һәм башка аерым хезмәт шартлары булган эшләр башкару белән шөгыльләнүче хезмәткәрләр санына киметү өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль законның 21 статьясына үзгәреш кертү хакында» 182753-6 номерлы федераль закон проектын (инвалид-

ларны эшкә урнаштыру өчен квота бирелгән эш урыннары санын исәпләгәндә оешма хезмәткәрләренең санын авыр эшләр, зарарлы һәм (яисә) хәвефле һәм башка аерым хезмәт шартлары булган эшләр башкару белән шөгыльләнүче хезмәткәрләр санына киметү өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 31 гыйнвары
№ 2677-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 43. Хезмәткә сәләтсез гражданнарны караучы эшләмәүче затларга компенсация түләүләрен җайга салучы гамәлдәге норматив актларны үзгәртү мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министры М.А. Топилинга Оренбург өлкәсе Закон чыгару Собраниесе депутатлары мөрәҗәгате турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Хезмәткә сәләтсез гражданнарны караучы эшләмәүче затларга компенсация түләүләрен җайга салучы гамәлдәге норматив актларны үзгәртү мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министры М.А. Топилинга Оренбург өлкәсе Закон чыгару Собраниесе депутатлары мөрәҗәгатен хупларга.

2. Әлеге карарны Оренбург өлкәсе Закон чыгару Собраниесенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 31 гыйнвары
№ 2678-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 44. «Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләрнең финанс ягын хәл итү турында» Федераль законның 20.1 статьясына үзгәреш кертү хакында» 185943-6 номерлы федераль закон проекты турында (бурычларны каплауны кичектерү срогын арттыру өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләрнең финанс ягын хәл итү турында» Федераль законның 20.1 статьясына үзгәреш кертү хакында» 185943-6 номерлы федераль закон проектын (бурычларны каплауны кичектерү срогын арттыру өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 31 гыйнвары
№ 2679-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 45. «Россия Федерациясе Җир кодексының 28 статьясына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Карелия Республикасы Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясе Җир кодексының 28 статьясына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Карелия Республикасы Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Карелия Республикасы Закон чыгару Собраниесенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәмmәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 31 гыйнвары
№ 2680-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 46. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 177474-6 номерлы федераль закон проекты турында (даими рәвештә пассажирлар йөртү өлкәсендә муниципаль контроль турында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 177474-6 номерлы федераль закон проектын (даими рәвештә пассажирлар йөртү өлкәсендә муниципаль контроль турында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Оренбург өлкәсе Закон чыгару Собраниесенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәмmәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 31 гыйнвары
№ 2681-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 47. «Россия Федерациясендә чит ил гражданнарының хокукый хәле турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 184699-6 номерлы федераль закон проекты турында (Россия Федерациясендә чит ил гражданы яисә гражданлыгы булмаган зат белән хезмәт шартнамәсен төзү рөхсәт ителгән яшь критерие буларак 18 яшьне билгеләү турында, шулай ук чит ил гражданына яисә гражданлыгы булмаган затка Россия Федерациясендә эшләүгә рөхсәт бирүдән яисә физик затларда хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыру хокукына патент бирүдән баш тарту йә аларда булган рөхсәтне яисә патентны юкка чыгару өчен өстәмә нигез буларак чит ил хезмәткәренең 18 яшькә җитмәвен күрсәтүне билгеләү хакында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясендә чит ил гражданнарының хокукый хәле турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 184699-6 номерлы федераль закон проектын (Россия Федерациясендә чит ил гражданы яисә гражданлыгы булмаган зат белән хезмәт шартнамәсен төзү рөхсәт ителгән яшь критерие буларак 18 яшьне билгеләү турында, шулай ук чит ил гражданына яисә гражданлыгы булмаган затка Россия Федерациясендә эшләүгә рөхсәт бирүдән яисә физик затларда хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыру хокукына патент бирүдән баш тарту йә аларда булган рөхсәтне яисә патентны юкка чыгару өчен өстәмә нигез буларак чит ил хезмәткәренең 18 яшькә җитмәвен күрсәтүне билгеләү хакында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 31 гыйнвары
№ 2682-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 48. «Рәсми спорт ярышлары нәтиҗәләренә хокукый каршылыклы йогынтыны булдырмау максатларында «Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 200769-6 номерлы федераль закон проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Рәсми спорт ярышлары нәтиҗәләренә хокукый каршылыклы йогынтыны булдырмау максатларында «Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 200769-6 номерлы федераль закон проектын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 31 гыйнвары
№ 2683-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 49. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 176205-6 номерлы федераль закон проекты турында (муниципаль контрольне гамәлгә ашыру өлкәсендә закон таләпләрен бозган өчен административ җаваплылык билгеләү хакында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 176205-6 номер-

лы федераль закон проектын (муниципаль контрольне гамәлгә ашыру өлкәсендә закон таләпләрен бозган өчен административ җаваплылык билгеләү хакында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 31 гыйнвары
№ 2684-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 50. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 12.15 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 187796-6 номерлы федераль закон проекты турында (транспорт чарасының транспорт юлы өлешендә урнашуы, каршыга килгәндә юл бирешү яисә узып китү кагыйдәләрен бозган өчен җаваплылыкны көчәйтү турында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 12.15 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 187796-6 номерлы федераль закон проектын (транспорт чарасының транспорт юлы өлешендә урнашуы, каршыга килгәндә юл бирешү яисә узып китү кагыйдәләрен бозган өчен җаваплылыкны көчәйтү турында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 31 гыйнвары
№ 2685-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 51. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Х.Г. Миргалимов гарызнамәсе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Үзәкләштерелгән кадастр исәбе зарурлыгы һәм «Садовод № 11» коммерциячел булмаган бакчачылык ширкәте әгъзаларының җиргә конституциячел хокукларын тәэмин итү турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Х.Г. Миргалимовның гарызнамәсен Татарстан Республикасы Премьер-министры И.Ш. Халиковка җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 31 гыйнвары
№ 2686-IV ДС

# II
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЛАРЫ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 52. Татарстан Республикасы Дәүләт гимны текстының иң яхшы проектына конкурс үткәрү буенча комиссия эшенең йомгаклары турында

Татарстан Республикасы Дәүләт гимны текстының иң яхшы проектына конкурс үткәрү буенча комиссия рәисе, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Р.А. Ратникованың конкурсның һәм комиссия эшенең йомгаклары турында мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт гимны текстының иң яхшы проектына конкурс үткәрү буенча комиссия (алга таба – Комиссия) эшенең йомгаклары турында мәгълүматны һәм Комиссия тарафыннан тапшырылган Татарстан Республикасы Дәүләт гимны текстының иң яхшы проектын игътибарга алырга.

2. «Татарстан Республикасы Дәүләт гимны текстының иң яхшы проектына иҗади конкурс үткәрү турында» 2011 елның 15 декабрендәге 1946-IV ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары нигезендә үткәрелгән Татарстан Республикасы Дәүләт гимны текстының иң яхшы проектына иҗади конкурсны тәмамланган дип танырга.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты «Татарстан Республикасы дәүләт символлары турында» Татарстан Республикасы Законына Татарстан Республикасы Дәүләт гимны текстын өстәүне күздә тота торган үзгәрешләр кертү хакында закон проектын Татарстан Республикасы Дәүләт Советына карауга кертергә тиеш.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Р.А. Ратниковага йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 24 гыйнвары
№ 2638-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

## 53. Татарстан Республикасында балалар сәламәтлеген саклау турында

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы докладын, Татарстан Республикасында балалар сәламәтлеген саклау турындагы мәсьәлә буенча чыгышларны тыңлап фикер алышканнан соң, шулай ук Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика балалар клиник больницасы» сәламәтлек саклау дәүләт автономияле учреждениесенә бару йомгакларын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы түбәндәгеләрне билгеләп үтә.

«Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә балалар гаиләдә һәм социаль яктан имин булуларына бәйсез рәвештә махсус саклanырга тиеш, моңа аларның сәламәтлеге турында кайгырту һәм сәламәтлек саклау өлкәсендә аларны тиешенчә хокукый яклау да керә.

Россия Федерациясендә балаларның хәлен яхшырту буенча дәүләт сәясәтен формалаштыру максатларында Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 1 июнендәге 761 номерлы Указы белән Балалар мәнфәгатьләрендә эш итүнең 2012 – 2017 елларга илкүләм стратегиясе расланды, Балалар мәнфәгатьләрендә эш итүнең республика стратегиясе (программасы) тиешле проекты эшләнде, һәр баланың сәламәтлеген саклау аларның төп принципларының берсе булып тора.

2012 елда Татарстан Республикасында балалар сәламәтлеген саклау чаралары сәламәтлек саклау өлкәсендә илкүләм өстенлекле проект, «2011 – 2012 елларга Татарстан Республикасында сәламәтлек саклауны модернизацияләү» программасы, 2011 – 2013 елларга «Татарстан балалары» озак сроклы максатчан программасы, 2010 – 2015 елларга Татарстан Республикасында мәгарифне үстерү «Киләчәк – Будущее» стратегиясе һәм башка, шул исәптән ведомство программалары кысаларында гамәлгә ашырылды.

Татарстан Республикасында балалар (0 – 17 яшь) саны 724 020 тәшкил итә, Татарстан Республикасында соңгы биш елда туучылар санының артуы күзәтелә һәм аның темплары Россия Федерациясендә тулаем алганга караганда югарырак.

2012 елда республикада 55 839 бала туган, бу 2011 елда туган балалар саныннан 5 062 балага күбрәк. Яңа туган балаларның бары 4,0 % гына тулысынча сау-сәламәт. Мәктәпкәчә балалар учреждениеләренә керер алдыннан сәламәтлек ягыннан беренче төркемгә 15,6 % балалар кергән, мәктәпкә укырга кергәндә сәламәт балалар өлеше 12,8 %, мәктәпне тәмамлаганда 10,2 % тәшкил иткән. Татарстан Республикасында инвалид балаларның саны 13 797 тәшкил иткән.

2011 елда алкоголь, наркотик матдәләр белән кирәгеннән артык мавыгуга бәйле рәвештә профилактик исәпкә алынган 15 яшькә кадәрге балалар саны кимегән, ВИЧ-инфекция, психик тайпылышлар белән авырулар саны азайган. Әмма агулы матдәләр белән кирәгеннән артык мавыгучы балалар саны арту тенденциясе саклана. Туберкулез, онкологик һәм дәвалану өчен шактый зур финанс чыгымнары таләп итeлә торган орфан (сирәк) авырулар белән авыручы балалаларның саны арткан.

Балаларга медицина ярдәмен «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика балалар клиник больницасы» сәламәтлек саклау дәүләт автономияле учреждениесе, 7 шәһәр балалар больницасы, 12 амбулатор поликлиника учреждениесе, 43 үзәк район больницасы, 5 балалар шифаханәсе, 6 балалар стоматология поликлиникасы, республика медицина учреждениеләре, шул исәптән махсуслаштырылган, балалар өчен 6 сәламәтлек үзәге, бер махсуслаштырылган балалар йорты, 1 792 фельдшер-акушерлык пункты күрсәтә.

Шуның белән бергә, сәламәтлек саклау учреждениеләрен балалар белгечлекләре буенча квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү мәсьәләсе актуаль булып кала. Табибларга кытлык – 28,5 %, участок шәфкать туташларына 15,4 % тәшкил итә.

Планлы диспансеризация үткәрү йомгаклары буенча дәвалау һәм савыктыру чараларын уздыру өлешендә ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга медицина ярдәмен күрсәтү мәсьәләләре махсус игътибар таләп итә. Югары технологияле медицина ярдәме күрсәтелүгә, шул исәптән Россия Федерациясеннән читтәге клиникаларда, мохтаҗ ятим балаларны исәпкә алуны оештырырга кирәк.

Балалар сәламәтлеген саклау мәсьәләләре гомуми белем бирү учреждениеләре эшчәнлегенең дә аерылгысыз өлеше булып тора. Республикада һәр ел сәламәтлеккә ярдәм итүче мәктәпләр челтәре арта. Хәзерге көндә 1 589 гомуми белем бирү учреждениесеннән 1 129 шундый мәктәп эшли.

Республика мәктәпләрендә «Мәктәп балаларының сәламәтлегендә тайпылышларны вакытыннан элек ачыклау» проекты гамәлгә ашырыла, «Сәламәтлеккә юл» бәйгесе, наркотик чараларны һәм психотроп матдәләрне куллануны ачыклау буенча профилактик медицина тикшерүләре, 14 яшьлек үсмерләргә, ятим балаларга һәм авыр тормыш хәлендәге балаларга тирәнәйтелгән диспансерлаштыру үткәрелә (2012 елда 14 яшьлек 34 236 бала тикшерелгән), «Дөрес туклану турында сөйләшү» программасы гамәлгә ашырыла.

Балалар һәм яшүсмерләрнең үз-үзләрен тотышында суицидаль чагылышларны профилактикалау максатларында (2012 елда мәктәп балалары арасында 16 суицид очрагы теркәлгән) фәнни-гамәли конференцияләр, квалификацияне күтәрү курслары, республика ата-аналар җыелышлары үткәрелә, укыту модуле һәм ата-аналар өчен лекторийлар оештырылган.

Шуның белән бергә, хәзерге көндә педагог-психологлар бары 368 шәһәр мәктәбендә генә эшли (авыл районнарында барысы 31 кеше). Аксубай, Алексеевск, Әтнә, Югары Ослан, Чүпрәле, Кайбыч, Лаеш, Яңа Чишмә, Теләче муниципаль районнары урта гомуми белем бирү мәктәпләрендә педагог-психологлар юк.

Гомуми белем бирү учреждениеләрендә медицина хезмәтен күрсәтүне оештыру медицина кабинетлары һәм медицина пунктлары базасында 636 мәктәптә гамәлгә ашырыла, 1 288 гомуми белем бирү учреждениесенә фельдшер-акушер пунктлары хезмәт күрсәтә. Әмма 2012 елның 1 декабренә бары 221 медицина кабинетының гына тиешле лицензиясе бар.

Лицензия алу проблемасы җирле бюджетларда медицина кабинетларын җиһазландыруга финанслар булмавына, булган медицина кабинетларының мәйданнары нормативларына, гомуми белем бирү учреждениесе штатына медицина хезмәткәрләрен кертү кирәклегенә бәйләнгән. Республика мәктәпләрендә эшләүче медицина персоналының хезмәт хакы элеккечә түбән булып кала.

Укучыларның сәламәтлеген саклау һәм ныгытуга ярдәм итә торган эшчәнлекнең төп юнәлешләреннән берсе булып гомуми белем бирү учреждениеләрендә кайнар баланслаштырылган туклануны оештыру тора, моның белән хәзерге көндә укучыларның 94 % тәэмин ителгән. Республиканың аерым муниципаль берәмлекләрендә социаль якланмаган гаиләләрдәге укучыларны түләүсез ашату оештырылган.

Укучылар сәламәтлеген саклауның әһәмиятле тармагы булып физик культура һәм спорт тора. Балаларның 94,4 % муниципаль берәмлекләрнең спорт-сәламәтләндерү объектлары, шул исәптән универсиада объектлары инфраструктурасын файдаланып, дәрестә һәм дәрестән тыш вакытта массакүләм физкультура белән шөгыльләнә. Физкультура-спорт юнәлешле берләшмәләр һәм секцияләргә 169 800 бала һәм яшүсмер йөри.

Республикада мәктәп балаларын физкультура һәм спорт белән актив шөгыльләнүгә җәлеп итүгә, балигъ булмаганнар арасында асоциаль күренешләрне профилактикалауга юнәлгән проектлар гамәлгә ашырыла, президент спорт уеннары һәм ярышлары, мәктәп баскетбол лигасының һәм мини-футбол буенча чемпионатлары, республика бәйгеләре һәм акцияләре үткәрелә.

Балалар һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен һәм эш белән тәэмин ителүен оештыру программалары кысаларында һәр елны чаралар үткәрелә. 2012 елда сәламәтләндерү кампаниясенә 1 256 644,0 мең сум юнәлдерелгән, республика шифаханә-курорт учреждениеләренә юлламалар алуга Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына 28 224,0 мең сум бүлеп бирелгән. Сәламәтләнү мөмкинлеген, шул исәптән «Ана һәм бала» юлламалары буенча, 1 021 бала алган. 2012 елда федераль бюджет акчалары исәбенә федераль шифаханәләргә 156 бала җибәрелгән.

2012 елда барлык төрдәге 1 334 лагерьда барысы 217 925 кеше ял иткән һәм сәламәтләнгән. Аерым игътибар авыр тормыш хәлендәге балаларның ялына бирелгән (12 819 кеше, шуларның 2 229ы – ятим балалар, 112се – инвалид балалар).

2012 елда онкология һәм башка төрле каты чирләр белән авырый торган балалар өчен Свияжск утравында сәламәтләндерү үзәге төзү турында карар кабул ителде.

Республикада алып барылган эшкә карамастан, балаларның җәйге ялын оештыруда күп кенә проблемалар бар. Мәктәп яны лагерьларында, бигрәк тә авыл җирендә, ял итүче балалар саны зур булып кала. Балалар лагерьлары матди-техник базасын модернизацияләү, аларда эшләүче медицина персоналының хезмәт хакын арттыру мәсьәләләре, шулай ук балалар сәламәтләндерү лагерьларында энергетик, сантехник һәм балта остасы ставкаларын тиешле санга җиткерү кирәклеге әһәмиятле булып кала. Шулай ук 2013 елда Казан шәһәрендә уздырылачак XXVII Бөтендөнья җәйге универсиадасын үткәрү чорында балалар лагерьларын саклау мәсьәләсе хәл итүне сорый.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасында балалар сәламәтлеген саклау турындагы мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

1) Балалар мәнфәгатьләрендә эш итүнең республика стратегиясен (программасын) кабул итүне тизләтергә;

2) түбәндәге сорауларны карарга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршында Татарстан Республикасында балалар сәламәтлеген саклау мәсьәләләре буенча ведомствоара координация советын (Хөкүмәт комиссиясен) оештыру турында;

сәламәт буын саклау, шул исәптән ятим балаларның һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларның сәламәтлеген саклау буенча чараларны күздә тотучы 2013 – 2017 елларга Татарстан Республикасы стратегиясен әзерләү һәм кабул итү турында;

балалар сәламәтләндерү шифаханә-курортларын финанслауны арттыру, шул исәптән «Ана һәм бала» юлламалары буенча, шулай ук шәһәр читендәге стационар лагерьларда койкакөннең норматив бәясен индексацияләү турында;

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү учреждениеләрен һәм балалар сәламәтләндерү лагерьларын кадрлар белән тәэмин итү мәсьәләләрен хәл итү буенча чаралар турында, шул исәптән аларда эшләүче медицина персоналына стимул бирә торган өстәмә түләүләр турында;

Татарстан Республикасында балалар сәламәтләндерү лагерьларының матди-техник базасын модернизацияләү турында;

3) 2013 елда Казан шәһәрендә уздырылачак XXVII Бөтендөнья җәйге универсиадасын үткәрү чорында балалар лагерьларында балаларны саклау һәм аларның иминлеген тәэмин итү буенча чаралар кабул итәргә.

3. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

1) сәламәтлек саклау өлкәсендә өстенлекле илкүләм проектны һәм Татарстан Республикасында балалар сәламәтлеген саклауга юнәлгән программаларны гамәлгә ашыру буенча эшне дәвам итәргә;

2) сәламәтлек саклау учреждениеләрен балалар белгечлекләре буенча квалификацияле медицина кадрлары белән тулыландыру буенча чаралар кабул итәргә.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

1) укучыларның сәламәт булуына ярдәм итүче мәктәпләр челтәрен үстерү, мәктәпләрне спорт инвентаре һәм җиһазлары, медицина җиһазлары белән тәэмин итү эшен дәвам итәргә;

2) Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белән бергә укучыларны сәламәтләндерүгә юнәлгән проектларны гамәлгә ашыруны дәвам итәргә;

3) мәктәп психолог-педагогик хезмәтен үстерү буенча чаралар кабул итәргә;

4) республиканың гомуми белем бирү учреждениеләре спорт залларында ремонт эшләрен үткәрүне тәэмин итәргә.

5. Татарстан Республикасындагы җирле үзидарә органнарына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

1) профилактика чараларын алга таба үстерүгә һәм алардан файдалану мөмкинлеген арттыруга, белем бирү һәм балаларны сәламәтләндерүнең җәйге учреждениеләрендә сәламәтлекне саклый торган һәм имин мохит формалаштыруга шартлар тудырырга;

2) муниципаль җирлекләрнең бюджетларын төзегәндә гомуми белем бирү учреждениеләренә медицина җиһазлары алу өчен, алардагы медицина кабинетларын оештыру һәм яңадан төзү өчен акчаларны исәпкә алырга;

3) гомуми белем бирү учреждениеләрендә медицина кабинетларына лицензия алу һәм аларны җиһазлау эшен дәвам итәргә;

4) район белем бирү учреждениесен тәмамлаучыларны медицина белем бирү учреждениеләренә максатчан җибәрү һәм аларның соңыннан урыннарда хезмәткә урнашу мәсьәләләре буенча эшне көчәйтергә.

6. Сәламәтлек саклау өлкәсендә илкүләм проектны гамәлгә ашыруны тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясе һәм «Мәгариф» илкүләм проектын гамәлгә ашыруны тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясенә балалар мәнфәгатьләрендә эш итүнең милли стратегиясендә каралган чараларны гамәлгә ашыру турындагы мәсьәләне карарга.

7. «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгына сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауның яңа төрләрен, сәламәтлек саклау, эчкечелекне, тәмәке тартуны, наркотик һәм психотроп матдәләр куллануны профилактикалау мәсьәләләре буенча балалар һәм ата-аналар

өчен комплекслы мәгълүмати һәм белем бирү программаларын массакүләм мәгълүмат чараларында кертү мөмкинлеген карауны тәкъдим итәргә.

8. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, тиешле министрлыклар һәм ведомстволарга, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башлыкларына җибәрергә.

9. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты рәисе С.М. Захаровага йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 24 гыйнвары
№ 2639-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 54. Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз җиденче утырышын чакыру турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә**:

Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз җиденче утырышын 2013 елның 31 гыйнварында 10.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утырышлар залында чакырырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 24 гыйнвары
№ 2640-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

## 55. Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз җиденче утырышы каравына кертелүче мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә**:

Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз җиденче утырышы каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1. Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкилләрен вазыйфаларына билгеләп кую турында.

2. «2013 елга, 2014 һәм 2015 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 454-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

3. «Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредитлары бирү турындагы килешүләргә өстәмә килешүләрне раслау хакында» 455-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

4. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 1428-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (III укылыш).

5. «Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2391-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (III укылыш).

6. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 2435-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).

7. «Яшьләр һәм Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәте турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 6419-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).

8. Муниципаль хезмәт турында 1448-4 номерлы Татарстан Республикасы кодексы проекты хакында (I укылыш).

9. «Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турын-

да беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» 457-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

10. «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең уңдырышлылыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 16 статьясына үзгәреш кертү хакында» 453-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

11. «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 456-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

12. 2012 елда Татарстан Республикасы Хисап палатасы эше турында хисап.

13. Россия Федерациясе Конституция Судына Россия Федерациясе Граждан процессуаль кодексының 26 статьясындагы беренче өлешенең 2 пункты, 251 статьясындагы беренче, икенче һәм дүртенче өлешләре, 253 статьясындагы икенче һәм өченче өлешләре нигезләмәләренең конституциячеллеген тикшерү турында гарызнамәне кире алу хакында.

14. «Вөҗдан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 343 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 195229-6 номерлы федераль закон проекты турында (руханилар, дини персонал һәм дини оешмалар хезмәткәрләренә, шулай ук күрсәтелгән вазыйфаларга кандидатларга таләпләрне билгеләү хокукын дини оешмаларга бирү өлешендә).

15. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 5.63 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 168733-6 номерлы федераль закон проекты турында (административ хокук бозулар составларын төгәлләштерү өлешендә).

16. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 181965-6 номерлы федераль закон проекты турында (юл хәрәкәте өлкәсендә хокук бозуларны кабат кылган өчен җаваплылыкны көчәйтү өлешендә).

17. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 200753-6 номерлы федераль закон проекты хакында (торак урыннарындагы затларны Россия Федерациясендә фиктив теркәү өчен алшартларны бетерү максатларында һәм килгән урында яисә яшәгән урында Россия гражданнарын теркәү кагыйдәләрен бозган өчен һәм аларның Россия

Федерациясендә торак урыннарында теркәлмичә яшәгәннәре өчен административ җаваплылык билгеләү турында, шулай ук Россия гражданнарын килгән урында яисә яшәгән урында Россия Федерациясендә фиктив теркәгән өчен һәм Россия Федерациясендә чит ил гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган затларны торак урыннарында миграция исәбенә фиктив алган өчен җинаять җаваплылыгын билгеләү турында).

18. «Россия Федерациясе Җинаять кодексының 169 һәм $171^1$ статьяларына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Башкортостан Республикасы Дәүләт Җыелышы – Корылтаеның закон чыгару инициативасы хакында.

19. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 20.25 һәм 28.3 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Алтай Республикасы Дәүләт Советы – Эл Корылтаеның закон чыгару инициативасы турында.

20. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Ставрополь крае Думасының закон чыгару инициативасы турында.

21. «Россия Федерациясе Граждан кодексының өченче өлешендәге 1151 статьясына үзгәреш кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Удмурт Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы хакында.

22. «Электрон имза турында» Федераль законга үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Пермь крае Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында.

23. «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль законның 21 статьясына үзгәреш кертү хакында» 182753-6 номерлы федераль закон проекты турында (инвалидларны эшкә урнаштыру өчен квота бирелгән эш урыннары санын исәпләгәндә оешма хезмәткәрләренең санын авыр эшләр, зарарлы һәм (яисә) хәвефле һәм башка аерым хезмәт шартлары булган эшләр башкару белән шөгыльләнүче хезмәткәрләр санына киметү өлешендә).

24. Хезмәткә яраксыз гражданнарны карап торучы эшләмәүче затларга компенсация түләүләрен җайга салучы гамәлдәге норматив актларны үзгәртү мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министры М.А. Топилинга Оренбург өлкәсе Закон чыгару Собраниесе депутатлары мөрәҗәгате турында.

25. «Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләрнең финанс ягын хәл итү турында» Федераль законның 20.1 статьясына үзгәреш кертү хакында» 185943-6 номерлы федераль закон проекты турында.

26. «Россия Федерациясе Җир кодексының 28 статьясына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Карелия Республикасы Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы хакында.

27. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 177474-6 номерлы федераль закон проекты турында (даими рәвештә пассажирлар йөртү өлкәсендә муниципаль контроль турында).

28. Төрлесеннән.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 24 гыйнвары
№ 2641-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 56. 2013 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советы эшен оештыру буенча чараларның якынча планы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә**:

2013 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советы эшен оештыру буенча чараларның якынча планын расларга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 24 гыйнвары
№ 2643-IV ДС

# III
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЛАРЫ ҺӘМ БОЕРЫКЛАРЫ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

## 57. «Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирү турында

Татарстан Республикасының бердәм бәяләр һәм тарифлар сәясәтен үстерүдәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты Коммуналь комплекс даирәсендә җайга салу идарәсе коммуналь комплекс оешмаларында тарифлар һәм бәяләр бүлеге әйдәүче киңәшчесе | Салихова Фәрдия Хәйдәр кызына |

«Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 11 гыйнвар
№ ПУ-2

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

## 58. «Татарстан Республикасының Атказанган төзүчесе» дигән мактаулы исем бирү турында

Төзелеш өлкәсендәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» ачык акционер җәмгыятенең «Ямаш-нефть» нефть һәм газ чыгару идарәсе капиталь төзелеш бүлеге башлыгы | Нуретдинов Илдар Илгиз улына |

«Татарстан Республикасының Атказанган төзүчесе» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 11 гыйнвар
№ ПУ-3

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 59. «Татарстан Республикасының Атказанган табибы» дигән мактаулы исем бирү турында

Халык сәламәтлеген саклау эшендәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәтләре өчен:

| | |
|---|---|
| «Менделеевск үзәк район хастаханәсе» дәүләт автономияле сәламәтлек саклау учреждениесенең терапия бүлекчәсе мөдире, табиб-терапевты | Вәлиев Рәшит Мөхәммәтҗан улына |
| «Балык Бистәсе үзәк район хастаханәсе» дәүләт автономияле сәламәтлек саклау учреждениесенең терапия бүлекчәсе мөдире, табиб-терапевты | Гаязов Рамил Фатыйх улына |
| «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика наркология диспансеры» дәүләт автономияле сәламәтлек саклау учреждениесенең 5 нче стационар бүлекчәсе мөдире | Мельников Михаил Аркадьевичка |

«Татарстан Республикасының Атказанган табибы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 11 гыйнвар
№ ПУ-4

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 60. «Татарстан Республикасының Атказанган торак-коммуналь хуҗалыгы хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында

Татарстан Республикасының торак-коммуналь хуҗалыгы өлкәсендәге казанышлары өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары – торак-коммуналь хуҗалыгы, төзелеш, транспорт, энергетика, элемтә һәм юл хуҗалыгы бүлеге башлыгы | Нургатин Ранас Әнәс улына |

«Татарстан Республикасының Атказанган торак-коммуналь хуҗалыгы хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 11 гыйнвар
№ ПУ-5

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 61. «Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирү турында

Банк эшен үстерү һәм камилләштерүдәге казанышлары, күпьеллык намуслы хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| «Россия Саклык банкы» ачык акционер җәмгыятенең 4642 номерлы Саба бүлекчәсе 4642/043 номерлы өстәмә офисы юридик затларга кредит бирү секторы башлыгы | Төхбәтуллина Рәзилә Гарәфи кызына |

«Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 11 гыйнвар
№ ПУ-6

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 62. «Татарстан Республикасының Атказанган укытучысы» дигән мактаулы исем бирү турында

Мәгариф өлкәсендәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Кукмара аграр көллияте» урта һөнәри белем бирү дәүләт автономияле мәгариф учреждениесенең махсус фәннәр укытучысы | Шакиров Ринат Нәфикъ улына |

«Татарстан Республикасының Атказанган укытучысы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 11 гыйнвар
№ ПУ-7

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 63. Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында

Татарстан Республикасында физик культура һәм спортны үстерүгә зур өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| Республика махсуслаштырылган балалар-яшүсмерләр фехтование буенча Олимпия резервы спорт мәктәбе тренеры-укытучысы | Гыйлаҗева Наилә Фәйзрахман кызын |

Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 11 гыйнвар
№ ПУ-8

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 64. «Татарстан Республикасының Атказанган физик культура хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында

Татарстан Республикасында физик культураны һәм спортны үстерүдәге казанышлары һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| «Тасма» Олимпия резервы махсуслаштырылган балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» балаларга өстәмә белем бирү муниципаль автономияле мәгариф учреждениесенең җиңел атлетика буенча тренеры-укытучысы | Котдусов Равил Хәлил улына |

«Татарстан Республикасының Атказанган физик культура хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 11 гыйнвар
№ ПУ-9

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 65. Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга иминлексезлеге сәбәпле урнаштырылган карантинны бетерү турында

Терлекләрнең котыру белән  чирләвенең соңгы очрагыннан соң ике ай узуы, эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар уздырылу белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы нигезендә **карар бирәм**:

1. Терлекләр котыру  авырулы булганга иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерергә:

а) Татарстан Республикасының түбәндәге торак пунктлары территорияләрендә:

Балтач районының  Иске Көшкәт авылы;

Мөслим районының Тойгелде авылы;
Спас районының Никольский авылы;
Спас районының Чәчәкле авылы;
б) Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләрендә:
Татарстан Республикасы Мөслим районының Татарстан урамындагы 1-35 номерлы шәхси йорт хуҗалыклары; Рәшитов урамындагы 22-52 номерлы шәхси йорт хуҗалыклары; Набережная урамындагы 1-40 номерлы шәхси йорт хуҗалыклары; Кооператив урамындагы 124-142 номерлы шәхси йорт хуҗалыклары;
Казан шәһәрендәге Конечная урамы;
Әлки районының Базарлы Матак авылындагы Хәмидуллин урамы;
Сарман районының Сарман авылындагы Высотная урамы;
Әлмәт шәһәрендәге Тюленин урамы;
Аксубай районының Яңа Илдерәк авылындагы Көньяк урамы;
Балтач районының Югары Шубан авылындагы Үзәк урамы;
Биектау районының Биектау авылындагы Совхоз урамы;
Татарстан Республикасының «Лениногорск урманчылыгы» дәүләт казна учреждениесе Иске Куак участок урманчылыгының 10 нчы һәм 37 нче кварталлары;
Татарстан Республикасының «Алабуга урманчылыгы» дәүләт казна учреждениесе Лубян участок урманчылыгының 97 нче кварталы;
Әлмәт районының «Туган табигать» коммерциячел булмаган оешма Фонды Бутино-Шешминск аучылык хуҗалыгының 109 нчы кварталы;
Әлмәт районындагы гомуми кулланыштагы аучылык җирләренең 52 нче кварталы;
Татарстан Республикасының «Кызыл Йолдыз урманчылыгы» дәүләт казна учреждениесе Котлы Бүкәш участок урманчылыгының 48 нче кварталы;
Татарстан Республикасының «Минзәлә урманчылыгы» дәүләт казна учреждениесе Актаныш участок урманчылыгының 14 нче һәм 211 нче кварталлары;
Татарстан Республикасының «Кама урманчылыгы» дәүләт казна учреждениесе Шеморбаш участок урманчылыгының 14 нче кварталы;

Арча районының Зур Бирәзә авылы янындагы «Шора» аучылык хуҗалыгы;

Лаеш районының Идел-Кама аучылык хуҗалыгының 1 номерлы обходы;

Мамадыш районының «Урман һәм К» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте Кама аучылык хуҗалыгы;

Минзәлә районының «Химпром» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте Яңа Минзәлә аучылык хуҗалыгы;

Спас районының «КИМ» совхозы поселогы янындагы мөгезле эре терлек асрау өчен 1 номерлы файдаланылмаучы җәйге лагере;

Буа районының Адав-Толымбай авылы янындагы авыл хуҗалыгы җирләре;

Кама Тамагы районының Олы Салтык авылы янындагы урман полосасы.

2. Түбәндәгеләрнең үз көчләрен югалтуын танырга:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының Мөслим районы Тойгелде авылы территориясендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга аларның иминлексезлегә сәбәпле карантин кертү турында» 2012 елның 20 августындагы ПУ-683 номерлы Указының 1 пунктындагы «а» пунктчасы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә һәм Татарстан Республикасының аерым территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2012 елның 20 августындагы ПУ-685 номерлы Указының 1 пунктындагы «а» пунктчасының өченче абзацы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының Спас районының кайбер торак пунктларында һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2012 елның 27 октябрендәге ПУ-903 номерлы Указының 1 пунктындагы «а» пунктчасы, «б» пунктчасының икенче – уналтынчы һәм унсигезенче – егерме дүртенче абзацлары.

3. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 12 гыйнвар
№ ПУ-10

## 66. Татарстан Республикасы Президентының «1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 70 еллыгын бәйрәм итү турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында

1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 70 еллыгын Татарстан Республикасында бәйрәм итүгә әзерлек һәм аны уздыру буенча оештыру комитетының эшчәнлеген камилләштерү максатларында **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президентының «1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 70 еллыгын бәйрәм итү турында» 2012 елның 9 октябрендәге ПУ-861 номерлы Указына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына, «ТАТМЕДИА» ачык акционер җәмгыятенә, «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе» ачык акционер җәмгыятенә 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 70 еллыгын бәйрәм итүгә багышланган чаралар уздыруны массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны оештырырга.»;

б) 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 70 еллыгын Татарстан Республикасында бәйрәм итүгә әзерлек һәм аны уздыру буенча оештыру комитеты (алга таба – Оештыру комитеты) составыннан В.Г. Карузинны чыгарырга;

в) Оештыру комитеты составына кертергә:

Кадыйров Рөстәм Раиф улын – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Административ һәм хокук саклау органнары идарәсе башлыгын;

Сибагатуллин Айрат Миңнемулла улын – Татарстан Республикасы мәдәният министрын;

г) Оештыру комитеты әгъзасы А.М. Терентьевның вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесе».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 12 гыйнвар
№ ПУ-11

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 67. «Татарстан Республикасының Атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында

Халык сәламәтлеген саклаудагы казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш өлкәсендә федераль күзәтчелек хезмәте Татарстан Республикасы буенча идарәсенең дару чаралары һәм медицина билгеләнешендәге эшләнмәләр әйләнешенә контроль бүлеге башлыгы урынбасары | Сәйфуллина Гөлназ Марсель кызына |

«Татарстан Республикасының Атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 15 гыйнвар
№ ПУ-12

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 68. Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында

Урман хуҗалыгын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасының «Саба урманчылыгы» дәүләт казна учреждениесе җитәкчесе – урманчысы | Гыйззәтуллин Васыйл Нурулла улын |

Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 15 гыйнвар
№ ПУ-13

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 69. «Татарстан Республикасының Атказанган халыкны социаль яклау хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында

Халыкны социаль яклау өлкәсендәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| «Казан шәһәре» шәһәр округында Халыкка социаль ярдәм күрсәтү үзәге» социаль ярдәм күрсәтү дәүләт автономияле учреждениесе директоры | Ибраһимова Надежда Викторовнага |

«Татарстан Республикасының Атказанган халыкны социаль яклау хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 15 гыйнвар
№ ПУ-14

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 70. «Татарстан Республикасының Атказанган юристы» дигән мактаулы исем бирү турында

Законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытудагы, гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклаудагы казанышлары һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен:

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасының Түбән Кама шәһәр суды рәисе | Булатов Наил Нариман улына |
| Татарстан Республикасының Мамадыш район суды судьясы | Дәүләтбаева Миләүшә Миңнәхмәт кызына |

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасының Чаллы шәһәр суды рәисе урынбасары | Юнысов Хәлил Харис улына |

«Татарстан Республикасының Атказанган юристы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 15 гыйнвар
№ ПУ-15

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

## 71. М.Я. Моратов турында

Марат Яшәр улы Моратовны, башка эшкә күчүе сәбәпле, Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенең беренче урынбасары вазыйфасыннан азат итәргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 15 гыйнвар
№ ПУ-16

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

## 72. «Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирү турында

Финанс-икътисад эшчәнлегендәге казанышлары һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча идарәсе финанс-икътисад бүлеге җитәкчесе | Гарипова Сания Садретдин кызына |

«Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 16 гыйнвар
№ ПУ-18

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

## 73. «Татарстан Республикасының Атказанган юристы» дигән мактаулы исем бирү турында

Законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытудагы казанышлары өчен Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләре:

| | |
|---|---|
| Гражданнарны кабул итү һәм документлар белән тәэмин итү бүлеге җитәкчесе урынбасары | Әфләтунов Рамил Хамил улына |
| Түбән Кама шәһәре буенча тикшерү бүлеге җитәкчесе | Билалов Рамил Кашафетдин улына |
| Казан шәһәре Яңа Савиново районы буенча тикшерү бүлеге җитәкчесе | Салихов Ранил Наил улына |
| Криминалистика бүлеге җитәкчесе | Тимергалиев Илсур Мансур улына |

«Татарстан Республикасының Атказанган юристы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 16 гыйнвар
№ ПУ-19

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

## 74. Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында

Намуслы хезмәте, югары һөнәри осталыгы, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытуга зур өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү идарәсе җитәкчесенең беренче урынбасары | Зарипов Марат Наил улын |

Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 16 гыйнвар
№ ПУ-20

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 75. Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында

Намуслы хезмәте, югары һөнәри осталыгы, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытуга шәхси өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының икътисадый куркынычсызлык һәм коррупциягә каршы тору идарәсе башлыгы, полиция полковнигы | Сафиуллин Илдар Рәшит улын |

Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 16 гыйнвар
№ ПУ-21

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 76. «Татарстан Республикасының Атказанган эчке эшләр органнары хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында

Эчке эшләр органнарында күпьеллык намуслы хезмәте, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытуга зур өлеш кертүе, һөнәри осталыгы өчен

| | |
|---|---|
| Россия Эчке эшләр министрлыгының Бөгелмә районы буенча бүлеге башлыгы, полиция полковнигы | Хөснетдинов Илдар Наил улына |

«Татарстан Республикасының Атказанган эчке эшләр органнары хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 16 гыйнвар
№ ПУ-22

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 77. «Татарстан Республикасының Атказанган архитекторы» дигән мактаулы исем бирү турында

Архитектура һәм шәһәр төзелеше өлкәсендәге казанышлары, күпьеллык намуслы хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасының «Татинвест-гражданпроект» Баш территориаль проект-эзләнү фәнни-җитештерү фирмасы дәүләт унитар предприятиесе фәнни-җитештерү лабораториясе башлыгы | Евсеев Евгений Сергеевичка |

«Татарстан Республикасының Атказанган архитекторы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 16 гыйнвар
№ ПУ-23

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 78. «Татарстан Республикасының Атказанган юристы» дигән мактаулы исем бирү турында

Законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытудагы, гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклаудагы казанышлары, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| Идел буе округы федераль арбитраж суды рәисе урынбасары | Абдулвагапов Ракиф Габделмалик улына |

«Татарстан Республикасының Атказанган юристы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 16 гыйнвар
№ ПУ-24

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 79. Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында

Финанс-икътисад эшчәнлегендәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| «Түбән Кама нефтехим» ачык акционер җәмгыяте баш бухгалтеры | Яхин Илфар Рафыйк улын |

Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 16 гыйнвар
№ ПУ-25

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 80. «Татарстан Республикасының Атказанган халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсе хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында

Азык-төлек продукциясенең сыйфатына, аның куркынычсызлыгына дәүләт контролен тәэмин итүдәге, Татарстан Республикасы куллану базарында хокук бозуларны кисәтүдәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәтләре өчен Татарстан Республикасының этил спирты, алкогольле продукция җитештерүгә, аның әйләнешенә һәм сыйфатына дәүләт контролен тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау дәүләт инспекциясе хезмәткәрләре:

| | |
|---|---|
| Зеленодольск территориаль органының контроль-инспекция бүлеге башлыгы | Гайнуллина Рузалия Фидаил кызына |

Халык куллануы товарларының сыйфатын тикшереп тору бүлеге башлыгы — Сәрвәрова Наилә Наил кызына

«Татарстан Республикасының Атказанган халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсе хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 16 гыйнвар
№ ПУ-26

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 81. «Татарстан Республикасының Атказанган халыкны социаль яклау хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында

Пенсия белән тәэмин итү системасын үстерүгә һәм камилләштерүгә өлеш кертүе һәм намуслы хезмәте өчен

Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы Баулы шәһәре, Баулы һәм Ютазы районнары буенча идарәсе дәүләт учреждениесенең пенсияләр билгеләү, яңадан исәпләү һәм түләү бүлеге белгече-эксперты — Демидова Елена Васильевнага

«Татарстан Республикасының Атказанган халыкны социаль яклау хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 16 гыйнвар
№ ПУ-27

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 82. «Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирү турында

Пенсия белән тәэмин итү системасын үстерүгә һәм камилләштерүгә өлеш кертүләре һәм намуслы хезмәтләре өчен

| | |
|---|---|
| Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы Казан шәһәре Вахитов районындагы идарәсе дәүләт учреждениесе башлыгы | Арсланова Флида Зөфәр кызына |
| Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлекчәсе дәүләт учреждениесе бюджет бүлеге башлыгы | Вафин Эдуард Яфәс улына |

«Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 16 гыйнвар
№ ПУ-28

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 83. Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында

Урман хуҗалыгын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы министры | Мәһдиев Наил Гамбәр улын |

Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 17 гыйнвар
№ ПУ-29

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 84. «Татарстан Республикасының Атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында

Югары һөнәри осталыгы, рухи кыйммәтләрне, гаилә традицияләрен саклауга һәм үстерүгә өлеш кертүе өчен

«Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе» муниципаль казна учреждениесе Яңа-Савиново районы буенча ЗАГС бүлеге баш белгече — Мөхетдинова Гүзәл Рамазан кызына

«Татарстан Республикасының Атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 18 гыйнвар
№ ПУ-30

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 85. Татарстан Республикасы Президенты Аппараты структурасына һәм Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Президенты Аппараты эшчәнлеген камилләштерү максатларында **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президенты Аппаратында түбәндәге Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын бетерергә:

Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенең беренче урынбасары;

Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе секретариаты җитәкчесе;

Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесе;

Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе секретариаты җитәкчесе урынбасары.

2. Татарстан Республикасы Президенты Аппаратында түбәндәге Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын гамәлгә куярга:

Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесе;

Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе секретариаты җитәкчесе.

3. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары реестры турында» 2006 елның 18 гыйнварындагы ПУ-9 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 12 мартындагы ПУ-121 номерлы, 2010 елның 1 апрелендәге ПУ-183 номерлы, 2010 елның 10 июнендәге ПУ-378 номерлы, 2010 елның 30 июнендәге ПУ-416 номерлы, 2010 елның 3 августындагы ПУ-512 номерлы, 2010 елның 2 сентябрендәге ПУ-585 номерлы, 2011 елның 31 гыйнварындагы ПУ-34 номерлы, 2011 елның 20 июлендәге ПУ-360 номерлы, 2011 елның 5 октябрендәге ПУ-620 номерлы, 2011 елның 13 октябрендәге ПУ-646 номерлы, 2011 елның 30 ноябрендәге ПУ-774 номерлы, 2012 елның 20 февралендәге ПУ-126 номерлы, 2012 елның 24 маендагы ПУ-375 номерлы, 2012 елның 13 августындагы ПУ-649 номерлы, 2012 елның 20 августындагы ПУ-681 номерлы һәм 2012 елның 19 октябрендәге ПУ-880 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары реестрының 1 өлешендәге 1 бүлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а)

| | | |
|---|---|---|
| « | Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенең беренче урынбасары | 01-1-1-01[1]» |

позициясен төшереп калдырырга;

б)

| | | |
|---|---|---|
| « | Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе секретариаты җитәкчесе | 01-1-1-02[1]» |

позициясен түбәндәге эчтәлекле позициягә алмаштырырга:

| | | |
|---|---|---|
| « | Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесе | 01-1-1-02[1]»; |

в)

« Татарстан Республикасы Президенты департаменты җитәкчесе 01-1-1-04[1]»

позициясен төшереп калдырырга;

г)

« Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе секретариаты җитәкчесе урынбасары 01-1-1-09[1]»

позициясен түбәндәге эчтәлекле позициягә алмаштырырга:

« Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе секретариаты җитәкчесе 01-1-1-09[1]».

4. Татарстан Республикасы Президентының 2011 елның 5 октябрендәге ПУ-620 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2011 елның 30 ноябрендәге ПУ-774 номерлы, 2012 елның 18 гыйнварындагы ПУ-24 номерлы, 2012 елның 10 мартындагы ПУ-188 номерлы, 2012 елның 11 июлендәге ПУ-559 номерлы, 2012 елның 16 июлендәге ПУ-587 номерлы, 2012 елның 30 июлендәге ПУ-624 номерлы, 2012 елның 13 августындагы ПУ-649 номерлы, 2012 елның 20 августындагы ПУ-680 номерлы, 2012 елның 19 октябрендәге ПУ-880 номерлы һәм 2012 елның 29 ноябрендәге ПУ-1002 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Президенты Аппараты структурасына һәм хезмәткәрләренең чик санына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а)

«

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1[1]. | Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенең беренче урынбасары | 1 | |

»

позициясен төшереп калдырырга;

б)

**«Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе секретариаты**

| | | | |
|---|---|---|---|
| 9. | Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе урынбасары – секретариат җитәкчесе | 1 | |
| 10. | Секретариат җитәкчесе урынбасары | 1 | |
| 11. | Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе ярдәмчесе | 2 | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 12. | Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе референты | 1 | |
| 13. | Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе секретариаты баш киңәшчесе | 2 | |
| 14. | Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе секретариаты баш белгече | 1 | |
| | **Барлыгы** | 8 | |

»

сүзләрен һәм позицияләрен түбәндәге эчтәлекле сүзләргә һәм позицияләргә алмаштырырга:

**«Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе секретариаты**

| | | | |
|---|---|---|---|
| 9. | Секретариат җитәкчесе | 1 | |
| 10. | - | - | |
| 11. | Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе ярдәмчесе | 2 | |
| 12. | Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе референты | 1 | |
| 13. | Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе секретариаты баш киңәшчесе | 2 | |
| 14. | Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе секретариаты баш белгече | 1 | |
| | **Барлыгы** | **8** | |

»;

в)

**«Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты**

| | | | |
|---|---|---|---|
| 28. | Департамент җитәкчесе | 1 | |

»

сүзләрен һәм позициясен түбәндәге эчтәлекле сүзләргә һәм позициягә алмаштырырга:

**« Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты**

| | | | |
|---|---|---|---|
| 28. | Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе урынбасары – Департамент җитәкчесе | 1 | |

»;

г)

«

| | | | |
|---|---|---|---|
| | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ БУЕНЧА БАРЛЫГЫ** | **223** | |

»

позициясен түбәндәге эчтәлекле позициягә алмаштырырга:

«

| | | | |
|---|---|---|---|
| | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ БУЕНЧА БАРЛЫГЫ** | **221** | |

».

5. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт органнарында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының гомуми санын раслау турында» 2008 елның 23 июнендәге ПУ-300 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 5 мартындагы ПУ-124 номерлы, 2009 елның 13 июнендәге ПУ-328 номерлы, 2009 елның 13 ноябрендәге ПУ-606 номерлы, 2009 елның 17 ноябрендәге ПУ-611 номерлы, 2010 елның 22 мартындагы ПУ-158 номерлы, 2010 елның 21 апрелендәге ПУ-253 номерлы, 2010 елның 10 июнендәге ПУ-378 номерлы, 2010 елның 3 августындагы ПУ-512 номерлы, 2010 елның 11 октябрендәге ПУ-681 номерлы, 2010 елның 1 ноябрендәге ПУ-712 номерлы, 2010 елның 23 декабрендәге ПУ-855 номерлы, 2011 елның 15 гыйнварындагы ПУ-7 номерлы, 2011 елның 31 гыйнварындагы ПУ-33 номерлы, 2011 елның 3 февралендәге ПУ-42 номерлы, 2011 елның 23 мартындагы ПУ-143 номерлы, 2011 елның 11 апрелендәге ПУ-194 номерлы, 2011 елның 29 июлендәге ПУ-459 номерлы, 2011 елның 19 августындагы ПУ-508 номерлы, 2011 елның 5 сентябрендәге ПУ-543 номерлы, 2011 елның 5 октябрендәге ПУ-620 номерлы, 2011 елның 13 октябрендәге ПУ-646 номерлы, 2011 елның 25 октябрендәге ПУ-676 номерлы, 2011 елның 25 октябрендәге ПУ-677 номерлы, 2011 елның 25 ноябрендәге ПУ-748 номерлы, 2011 елның 30 ноябрендәге ПУ-774 номерлы, 2012 елның 18 гыйнварындагы ПУ-23 номерлы, 2012 елның 10 мартындагы ПУ-190 номерлы, 2012 елның 13 апрелендәге ПУ-257 номерлы, 2012 елның 11 июнендәге ПУ-460 номерлы, 2012 елның 23 июнендәге ПУ-495 номерлы, 2012 елның 27 июлендәге ПУ-622 номерлы, 2012 елның 30 июлендәге ПУ-624 номерлы, 2012 елның 13 августындагы ПУ-649 номерлы, 2012 елның 20 августындагы ПУ-680 номерлы, 2012 елның 23 августындагы ПУ-689 номерлы, 2012 елның 29 сентябрендәге ПУ-823 номерлы, 2012 елның 11 октябрендәге ПУ-871 номерлы, 2012 елның 19 октябрендәге ПУ-880 номерлы һәм 2012 елның 29 ноябрендәге ПУ-1002 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) 1 нче кушымтага, 1 пункттагы «213» санын «211» санына алмаштырып, үзгәреш кертергә.

6. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты Аппаратында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләгән затларның вазый-

фаи окладлары турында» 2006 елның 5 апрелендәге ПУ-142 номерлы Указына кушымтага (Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 13 мартындагы ПУ-128 номерлы, 2010 елның 19 апрелендәге ПУ-238 номерлы, 2010 елның 21 июнендәге ПУ-394 номерлы, 2010 елның 8 сентябрендәге ПУ-596 номерлы, 2011 елның 30 ноябрендәге ПУ-774 номерлы, 2012 елның 13 августындагы ПУ-649 номерлы һәм 2012 елның 19 октябрендәге ПУ-880 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән), Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын индексацияләү турында» 2007 елның 3 декабрендәге ПУ-647 номерлы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын индексацияләү турында» 2008 елның 3 октябрендәге ПУ-490 номерлы һәм «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын индексацияләү турында» 2012 елның 13 августындагы ПУ-646 номерлы указларының нигезләмәләрен исәпкә алып, түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а)

«

| | | |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенең беренче урынбасары | 01-1-1-01[1] | 9090 |

»

позициясен төшереп калдырырга;

б)

«

| | | |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе секретариаты җитәкчесе | 01-1-1-02[1] | 8665-9090 |

»

позициясен түбәндәге эчтәлекле позициягә алмаштырырга:

«

| | | |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесе | 01-1-1-02[1] | 9185-9636 |

»;

в)

«

| | | |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесе | 01-1-1-04[1] | 8613 |

»

позициясен төшереп калдырырга;

г)

«

| | | |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе секретариаты җитәкчесе урынбасары | 01-1-1-09[1] | 7575 |

»

позициясен түбәндәге эчтәлекле позициягә алмаштырырга:

«

| | | |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе секретариаты җитәкчесе | 01-1-1-09[1] | 8613 |

».

7. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты турында нигезләмәне раслау хакында» 2006 елның 20 мартындагы ПУ-114 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 12 мартындагы ПУ-121 номерлы, 2010 елның 1 апрелендәге ПУ-183 номерлы, 2011 елның 5 октябрендәге ПУ-622 номерлы, 2011 елның 30 ноябрендәге ПУ-774 номерлы, 2012 елның 13 августындагы ПУ-649 номерлы һәм 2012 елның 19 октябрендәге ПУ-880 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Президенты Аппараты турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 8 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе, Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенең беренче урынбасары һәм урынбасарлары» сүзләрен «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе һәм аның урынбасарлары» сүзләренә алмаштырырга;

б) 12 пунктта:

беренче абзацта:

«Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенең беренче урынбасары» сүзләрен төшереп калдырырга;

«Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе секретариаты җитәкчесе» сүзләрен «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесе» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе секретариаты җитәкчесе урынбасары» сүзләрен «Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе секретариаты җитәкчесе» сүзләренә алмаштырырга;

в) 15 пунктта «беренче» сүзен төшереп калдырырга.

8. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты турында» 2006 елның 5 апрелендәге ПУ-134 номерлы Указының (Татарстан Республикасы Президентының 2006 елның 16 июнендәге ПУ-223 номерлы, 2006 елның 10 ноябрендәге ПУ-466 номерлы, 2007 елның 21 июнендәге ПУ-323 номерлы, 2008 елның 29 августындагы ПУ-425 номерлы, 2010 елның 12 мартындагы ПУ-121 номерлы, 2010 елның 1 апрелендәге ПУ-183 номерлы, 2010 елның 12 июлендәге ПУ-445 номерлы, 2010 елның 25 декабрендәге ПУ-863 номерлы, 2011 елның 15 гыйнварындагы ПУ-7 номерлы, 2011 елның 30 ноябрендәге ПУ-774 номерлы, 2012 елның 30 июлендәге ПУ-624 номерлы, 2012 елның 13 августындагы ПУ-649 номерлы һәм 2012 елның 19 октябрендәге ПУ-880 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) 1 пунктындагы беренче абзацына, «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе, Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенең беренче урынбасары һәм урынбасарлары» сүзләрен «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе һәм аның урынбасарлары» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

9. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе секретариаты турында нигезләмәне раслау хакында» 2010 елның 19 апрелендәге ПУ-236 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе секретариаты турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе секретариаты җитәкчесе (алга таба – секретариат җитәкчесе) вазыйфага Татарстан Республикасы Президенты боерыгы белән билгеләп куела һәм вазыйфадан азат ителә.»;

б) 12 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе урынбасары – секретариат җитәкчесе» сүзләрен «Секретариат җитәкчесе» сүзләренә алмаштырырга;

в) 13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Секретариат җитәкчесе вакытлыча булмаган чорда секретариат хезмәткәрләре арасыннан секретариат җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы билгеләп куела.»;

г) 14 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе урынбасары – секретариат җитәкчесен» сүзләрен «секретариат җитәкчесен» сүзләренә алмаштырырга.

10. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен команди-

ровкага җибәрү тәртибе һәм шартлары турында» 2005 елның 9 сентябрендәге ПУ-366 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2008 елның 11 гыйнварындагы ПУ-3 номерлы, 2010 елның 12 июлендәге ПУ-445 номерлы, 2010 елның 14 октябрендәге ПУ-695 номерлы, 2010 елның 17 ноябрендәге ПУ-751 номерлы, 2011 елның 14 февралендәге ПУ-57 номерлы һәм 2011 елның 5 октябрендәге ПУ-627 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) 3 нче кушымтада «Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе секретариаты җитәкчесе урынбасары» сүзләрен «Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе секретариаты җитәкчесе» сүзләренә алмаштырырга.

11. Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенә законнар нигезендә билгеләнгән вакытта һәм тәртиптә әлеге Указны гамәлгә ашыру буенча оештыру-штат чаралары күрергә.

12. Үз көчләрен югалтуын танырга:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты структурасына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 1 апрелендәге ПУ-183 номерлы Указының 4 пунктындагы икенче һәм өченче абзацлары;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты структурасына һәм аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» 2012 елның 13 августындагы ПУ-649 номерлы Указының 1 пункты.

13. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 18 гыйнвар
№ ПУ-31

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 86. А.М. Терентьевны Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесе итеп билгеләп кую турында

Александр Михайлович Терентьевны, элек биләгән вазыйфасыннан азат итеп, Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республи-

касы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесе итеп билгеләп куярга.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 18 гыйнвар
№ ПУ-32

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 87. Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында

Терлекләрнең котыру авырулы булуы ачыклану һәм аның Татарстан Республикасы торак пунктларында таралу куркынычы белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» Россия Федерациясе Законының $3^1$, 17 статьялары нигезендә **карар бирәм**:

1. Терлекләр котыру авырулы булганга аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертергә:

а) Татарстан Республикасының түбәндәге торак пунктлары территорияләрендә:

Әлки районының Аппак авылы;

Бөгелмә районының Берлек авылы;

б) Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләрендә:

Әлмәт районының Колшәрип авылындагы Гыйльфанов урамы;

Әлмәт районының Тайсуган авылындагы Вахитов урамы;

Яңа Чишмә районының Яңа Чишмә авылындагы Ленин урамы;

Тәтеш районының Олы Шәмәк авылындагы Мәктәп урамы;

Балтач районы Шөңшеңәр авылының Тукай урамындагы 58-65 номерлы шәхси йорт хуҗалыклары;

Яңа Чишмә районының «Красный Октябрь» совхозы поселогы янындагы «Зубов В.С.» крестьян (фермер) хуҗалыгының мөгезле эре терлек асрау өчен файдаланылучы территориясенең бер өлеше;

Тукай районының Сәет авылы янындагы «Ирек» производство кооперативының бозаулар үстерү өчен файдаланылучы территориясенең бер өлеше;

Бөгелмә районы Березовка авыл җирлегенең Солдат Писмәнкәсе авылыннан төньяк юнәлештә 4 километр ераклыкта урнашкан 1,5 гектар мәйдандагы җирләре;

Бөгелмә районы Березовка авыл җирлегенең Солдат Писмәнкәсе авылыннан көньяк-көнбатыш юнәлештә 3 километр ераклыкта урнашкан 1,5 гектар мәйдандагы җирләре.

2. Әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән территорияләрдә карантин гамәле дәвам иткән вакытта түбәндәгеләр тыела:

йорт хайваннарын сату, аларны әлеге территориядән читкә чыгару һәм кыргый җәнлекләрне (аларны зоопаркларга чыгару өчен, башка районнарда үрчетү максатларында) тоту;

котыру авырулы яисә авыру дигән шик тудырган хайваннарны ит өчен сую;

котыру авырулы терлекләрнең сөтен сату, ризыкка куллану һәм хайваннарга ашату;

клиник сәламәт терлекләрнең билгеләнгән тәртиптә пастеризацияләнмәгән сөтен сату, ризыкка куллану һәм хайваннарга ашату;

клиник сәламәт терлекләрнең билгеләнгән тәртиптә дезинфекцияләнмәгән йонын, тиресен әлеге территориядән чыгару.

3. Карантин, зарури чаралар күрү шарты үтәлгәндә, терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагы көненнән ике ай вакыт узгач бетерелергә тиеш, дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән территорияләрдә терлекләрнең котыру белән чирләвен бетерү буенча чаралар планнарын эшләргә һәм расларга, шулай ук аның гамәлгә ашырылуын тәэмин итәргә.

5. Әлеге Указның үтәлешенә контрольне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына йөкләргә.

6. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 18 гыйнвар
№ ПУ-33

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 88. «Татарстан Республикасының Атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирү турында

Театр сәнгатен үстерүгә зур өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| «Казан дәүләт яшь тамашачы театры» дәүләт бюджет учреждениесе артисты | Калаганова Елена Александровнага |

«Татарстан Республикасының Атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 18 гыйнвар
№ ПУ-34

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 89. «Татарстан Республикасының Атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирү турында

Музыка сәнгатен үстерүгә зур өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| «Бәрмәнчек» керәшен дәүләт фольклор ансамбле» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе сәнгать җитәкчесе | Кашапова Эльмира Вафа кызына |

«Татарстан Республикасының Атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 18 гыйнвар
№ ПУ-35

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 90. Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында

Халык сәламәтлеген саклау эшенә лаеклы өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры | Фәррахов Айрат Зәки улын |

Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 18 гыйнвар
№ ПУ-36

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 91. «Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирү турында

Авыл хуҗалыгы өлкәсендә финанс-икътисад эшчәнлегендәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| «Татарстанның элита орлыклары» ассоциациясенең исәп-хисап – финанс бүлеге башлыгы | Мәүлин Вәзир Рәкыйп улына |

«Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 18 гыйнвар
№ ПУ-37

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 92. «Татарстан Республикасының Атказанган юристы» дигән мактаулы исем бирү турында

Законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытудагы казанышлары, күпьеллык нәтиҗәле фәнни-педагогик эшчәнлеге өчен

«Казан (Идел буе) федераль университеты» югары һөнәри белем бирү федераль автоном мәгариф учреждениесе юридик факультетының җинаять процессы һәм криминалистика кафедрасы доценты — Якушин Станислав Юрьевичка

«Татарстан Республикасының Атказанган юристы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 18 гыйнвар
№ ПУ-38

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

## 93. «Татарстан Республикасының Атказанган юристы» дигән мактаулы исем бирү турында

Законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытудагы, гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклаудагы казанышлары, күпьеллык намуслы хезмәте өчен

«Юридик Белем бирү Үзәге» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры — Мөхәммәтов Камил Баязит улына

«Татарстан Республикасының Атказанган юристы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 18 гыйнвар
№ ПУ-39

## 94. Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга иминлексезлеге сәбәпле урнаштырылган карантинны бетерү турында

Терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагыннан соң ике ай узуы, эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар уздырылу белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы нигезендә **карар бирәм**:

1. Терлекләр котыру авырулы булганга иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерергә:

а) Татарстан Республикасының түбәндәге торак пунктлары территорияләрендә:

Азнакай районы Әгер авылы;

Балтач районы Сырия авылы;

Балтач районы Арбаш авылы;

Кукмара районы Янсыбы авылы;

Кукмара районы Ядегәр авылы;

Тукай районы Останково авылы;

Тукай районы Мөрес авылы;

б) Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләрендә:

Әлмәт районының Рус Акташы авылындагы Яр буе урамы;

Апас районының Бакырчы авылындагы Ленин урамы;

Арча районының Яңа Кенәр авылындагы Куйбышев урамы;

Зәй районының Якты Күл авылындагы Ленин урамы;

Зәй районының Бура-Киртә авылындагы Үзәк урам;

Кайбыч районының Олы Кайбыч авылындагы Яр буе урамы;

Саба районының Олы Кибәче авылындагы Гагарин урамы;

Саба районының Югары Симет авылындагы Тукай урамы;

Теләче районының Теләче авылындагы Алабуга урамы;

Казан шәһәрендәге Варшава урамы;

Чистай районындагы «Тиен» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Багана аучылык хуҗалыгы;

Түбән Кама районы Шенгәлче авыл җирлегенең Шенгәлче авылыннан төньяк-көнбатыш юнәлештә 400 метр ераклыкта урнашкан 2 гектар мәйдандагы җирләре;

Буа районы Кайбыч авыл җирлегенең Кайбыч авылыннан көнбатыш юнәлештә 3 километр ераклыкта урнашкан 2 гектар мәйдандагы җирләре;

Татарстан Республикасының «Идел буе урманчылыгы» дәүләт казна учреждениесе Чулпаниха участок урманчылыгының 68 нче кварталы;

Яңа Чишмә районындагы «Полюс» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте «Бөркет» аучылык хуҗалыгының 4 нче кварталы.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территориясендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2012 елның 12 ноябрендәге ПУ-949 номерлы Указының үз көчен югалтуын танырга.

3. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 21 гыйнвар
№ ПУ-40

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

## 95. «Татарстан Республикасының Атказанган ветеринария табибы» дигән мактаулы исем бирү турында

Республикада ветеринария хезмәтен үстерүдәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе дәүләт ветеринария күзәтчелеге бүлеге дәүләт инспекторы | Бонифатьев Евгений Павловичка |

«Татарстан Республикасының Атказанган ветеринария табибы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 23 гыйнвар
№ ПУ-41

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 96. Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында

Законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгыту, гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау эшендәге казанышлары, күпьеллык намуслы хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәр прокуроры | Брынза Сергей Петровичны |

Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 24 гыйнвар
№ ПУ-42

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 97. «Татарстан Республикасының Атказанган юристы» дигән мактаулы исем бирү турында

Законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытудагы, гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклаудагы казанышлары, күпьеллык намуслы хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы прокуратурасының судларда җинаять эшләрен караганда прокурорлар катнашуын тәэмин итү идарәсе башлыгы урынбасары – күзәтчелек бүлеге башлыгы | Гусев Виктор Владимировичка |

«Татарстан Республикасының Атказанган юристы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 24 гыйнвар
№ ПУ-43

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

## 98. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил турында

Татарстан Республикасында эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил институты формалаштыру максатларында карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил вазыйфасын гамәлгә куярга.

2. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил вазыйфага Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан билгеләп куела һәм вазыйфадан азат ителә.

3. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил түбәндәге вәкаләтләрне тормышка ашыра:

Татарстан Республикасында эшкуарлык эшчәнлеге субъектларының (алга таба – гариза бирүчеләрнең) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының, аларның вазыйфаи затларының карарларына һәм (яисә) гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләрен карый, гариза бирүчеләрне (әгәр дә гариза бирүче оешма булса, аларның вәкилләрен) шәхсән кабул итә;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органына, җирле үзидарә органына, аларның вазыйфаи затларына, ул үзе аларның карарларында һәм (яисә) гамәлләрендә (гамәл кылмауларында) гариза бирүченең хокуклары бозылуны һәм законлы мәнфәгатьләре бозылуны ачыкласа, күрсәтелгән хокукларны һәм законлы мәнфәгатьләрне торгызуның мөмкин булган һәм зарури чараларына карата тәкъдимнәре булган бәяләмәсен җибәрә;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органы, җирле үзидарә органы җитәкчесенә гариза бирүченең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуларны бетерү һәм (яисә) гариза бирүченең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуга юл куйган вазыйфаи затларына дисциплинар җәза куллану буенча чара күрү турында мөрәҗәгать итә;

дәүләт хакимиятенең компетентлы органнарына, әгәр алар, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эш-

куарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил фикере буенча, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органының вазыйфаи заты, җирле үзидарә органының вазыйфаи заты карарларында һәм (яисә) гамәлләрендә (гамәл кылмауларында) административ хокук бозу яисә җинаять составы билгеләре булу турында таныкласа, шикаятьне тикшерү барышында алынган материалларны җибәрә;

дәүләт хакимиятенең компетентлы органнарына, әгәр алар, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил фикере буенча, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органының, җирле үзидарә органының һәм аларның вазыйфаи затларының карарларында һәм (яисә) гамәлләрендә (гамәл кылмауларында) күрсәтелгән компетентлы органнар тарафыннан аларның вәкаләтләре нигезендә чара күрү өчен нигез булуы турында таныкласа, шикаятьне тикшерү барышында алынган материалларны җибәрә.

4. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары реестры турында» 2006 елның 18 гыйнварындагы ПУ-9 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 12 мартындагы ПУ-121 номерлы, 2010 елның 1 апрелендәге ПУ-183 номерлы, 2010 елның 10 июнендәге ПУ-378 номерлы, 2010 елның 30 июнендәге ПУ-416 номерлы, 2010 елның 3 августындагы ПУ-512 номерлы, 2010 елның 2 сентябрендәге ПУ-585 номерлы, 2011 елның 31 гыйнварындагы ПУ-34 номерлы, 2011 елның 20 июлендәге ПУ-360 номерлы, 2011 елның 5 октябрендәге ПУ-620 номерлы, 2011 елның 13 октябрендәге ПУ-646 номерлы, 2011 елның 30 ноябрендәге ПУ-774 номерлы, 2012 елның 20 февралендәге ПУ-126 номерлы, 2012 елның 24 маендагы ПУ-375 номерлы, 2012 елның 13 августындагы ПУ-649 номерлы, 2012 елның 20 августындагы ПУ-681 номерлы, 2012 елның 19 октябрендәге ПУ-880 номерлы һәм 2013 елның 18 гыйнварындагы ПУ-31 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары реестрының 1 өлешендәге 1 бүлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

| | | |
|---|---|---|
| « | Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советында вәкаләтле вәкиле** | 01-1-1-03» |

позициясеннән соң түбәндәге эчтәлекле позиция өстәргә:

« Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил 01-1-1-03[1]».

5. Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенә ун көн вакыт эчендә Татарстан Республикасы Президенты актларын әлеге Указга туры китерү буенча тәкъдимнәр кертергә.

6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына «Россия Федерациясендә эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилләр турында» федераль законның үз көченә керүе көненнән утыз көн вакыт эчендә Татарстан Республикасында Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил турында Татарстан Республикасы законы проектын эшләргә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кертергә.

7. Әлеге Указ рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 24 гыйнвар
№ ПУ-44

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 99. «Татарстан Республикасының Атказанган мелиораторы» дигән мактаулы исем бирү турында

Мелиорация өлкәсендәге казанышлары, күпьеллык намуслы хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| «Татмелиоводхоз» идарәсе» федераль дәүләт бюджет учреждениесе филиалы – Мелиорация һәм су хуҗалыгы төзелеше дирекциясе («Татмелиоводстрой» дирекциясе) баш инженеры, Казан шәһәре | Ханов Илдус Локман улына |

«Татарстан Республикасының Атказанган мелиораторы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 24 гыйнвар
№ ПУ-45

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

## 100. «Татарстан Республикасының Атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында

Агросәнәгать комплексы үсешенә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| «Татмелиоводхоз» идарәсе» федераль дәүләт бюджет учреждениесе директорының беренче урынбасары, Казан шәһәре | Рамазанов Азат Харрас улына |

«Татарстан Республикасының Атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 24 гыйнвар
№ ПУ-46

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

## 101. Т.Д. Нагумановны Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил итеп билгеләп кую турында

Тимур Дмитрий улы Нагумановны Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил итеп билгеләп куярга.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 25 гыйнвар
№ ПУ-47

## 102. Дәүләт, шул исәптән хәрби, һәм дәүләт аккредитациясенә ия дәүләтнеке булмаган мәгариф учреждениеләре аспирантлары, адъюнктлары, студентлары, курсантлары һәм укучылары өчен Татарстан Республикасының махсус дәүләт стипендияләрен билгеләү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасының дәүләт, шул исәптән хәрби, һәм дәүләт аккредитациясенә ия дәүләтнеке булмаган мәгариф учреждениеләре аспирантлары, адъюнктлары, студентлары, курсантлары һәм укучылары өчен Татарстан Республикасының махсус дәүләт стипендияләре комиссиясе тәкъдимнәрен карап, **карар бирәм**:

Уку һәм фәнни эшчәнлекләрендәге тырышлыклары һәм ирешкән уңышлары өчен 2011/2012 уку елы йомгаклары буенча 2012/2013 уку елына Татарстан Республикасының махсус дәүләт стипендияләрен билгеләргә:

1. Югары һөнәри белем дәүләт һәм дәүләт аккредитациясенә ия дәүләтнеке булмаган мәгариф учреждениеләре аспирантларына, адъюнктларына:

1) Алашкин Егор Михайловичка – Казан (Идел буе) федераль университеты аспирантына;

2) Александров Станислав Витальевичка – Казан (Идел буе) федераль университеты аспирантына;

3) Габдрахманов Динар Рәшит улына – Казан милли тикшеренү технология университеты аспирантына;

4) Гыйльманова Диләрә Мотыйгулла кызына – Казан (Идел буе) федераль университеты аспирантына;

5) Гимбицков Артур Вячеславовичка – А.Н. Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты – КАИ аспирантына;

6) Гошунова Анна Валерьевнага – Казан (Идел буе) федераль университеты аспирантына;

7) Закирова Альбина Булат кызына – Казан дәүләт энергетика университеты аспирантына;

8) Крылов Павел Сергеевичка – Казан (Идел буе) федераль университеты аспирантына;

9) Минеев Александр Николаевичка – Россия Федерациясе Граждан оборонасы, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәлаказаларны бетерү эшләре министрлыгының Дәүләт янгынга каршы көрәш хезмәте академиясе (Мәскәү шәһәре) адъюнктына;

10) Мөхәммәтҗанова Лениза Расих кызына – Казан (Идел буе) федераль университеты аспирантына;

11) Никифоров Николай Владимировичка – Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университеты аспирантына;

12) Никифоров Максим Олеговичка – А.Н. Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты – КАИ аспирантына;

13) Плаксимова Анжела Николаевнага – Икътисад, идарә һәм хокук институты (Казан шәһәре) аспирантына;

14) Просвирников Дмитрий Богдановичка – Казан милли тикшеренү технология университеты аспирантына;

15) Самарин Евгений Владимировичка – Казан милли тикшеренү технология университеты аспирантына;

16) Саттарова Зөлфия Габделәхәт кызына – Казан милли тикшеренү технология университеты аспирантына;

17) Сафин Тимур Рамил улына – Казан (Идел буе) федераль университеты аспирантына;

18) Туишева Мәрьям Равил кызына – А.Н. Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты – КАИ аспирантына;

19) Фәйзуллин Константин Владимировичка – А.Н. Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты – КАИ аспирантына;

20) Хазова Елена Владимировнага – Казан дәүләт медицина университеты аспирантына;

21) Хәйруллина Динара Николаевнага – Казан (Идел буе) федераль университеты аспирантына;

22) Чимитов Дмитрий Александровичка – «ТИСБИ» Идарә университеты аспирантына.

2. Югары һөнәри белем дәүләт, шул исәптән хәрби, һәм дәүләт аккредитациясенә ия дәүләтнеке булмаган мәгариф учреждениеләре студентлары һәм курсантларына:

1) Абросимов Александр Владимировичка – Казан милли тикшеренү технология университеты студентына;

2) Афанасьева Валентина Маратовнага – А.Н.Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты – КАИ студентына;

3) Афандеева Ксения Леонидовнага – Казан (Идел буе) федераль университеты студентына;

4) Ашаева Анастасия Валерьевнага – Казан (Идел буе) федераль университеты студентына;

5) Баһаутдинова Лилия Рөстәм кызына – Казан дәүләт аграр университеты студентына;

6) Бишбаев Фәррух Гайрәт улына – Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Россия хокук академиясе филиалы – Казан юридик институты студентына;

7) Борһанова Тәнзилә Фирүс кызына – Казан (Идел буе) федераль университеты студентына;

8) Галиуллин Руслан Наил улына – Казан (Идел буе) федераль университеты студентына;

9) Галиева Гадилә Рифкать кызына – А.Н. Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты – КАИ студентына;

10) Гәрәев Илдар Ирек улына – (Идел буе) федераль университетының Чаллы шәһәрендәге филиалы студентына;

11) Гәрәев Айдар Зәйтүн улына – Россия Федерациясе Граждан оборонасы, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казаларны бетерү эшләре министрлыгының Дәүләт янгынга каршы көрәш хезмәте Урал институты курсантына;

12) Гыйниятуллин Илфат Замир улына – Россия Федерациясе Граждан оборонасы, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казаларны бетерү эшләре министрлыгының Дәүләт янгынга каршы көрәш хезмәте Урал институты курсантына;

13) Гобәйдуллина Кристина Дамир кызына – Казан дәүләт медицина университеты студентына;

14) Дзамукова Мария Родионовнага – Казан (Идел буе) федераль университеты студентына;

15) Димиева Галия Рөстәм кызына – Түбән Кама муниципаль институты студентына;

16) Епишева Анастасия Дмитриевнага – Н.Э. Бауман исемендәге Казан дәүләт ветеринар медицина академиясе студентына;

17) Камалиев Альберт Рөстәм улына – Казан милли тикшеренү технология университеты студентына;

18) Кочкин Игорь Юрьевичка – А.Н.Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты – КАИ студентына;

19) Кузин Юрий Ивановичка – Казан (Идел буе) федераль университеты студентына;

20) Купчихина Мария Владимировнага – Казан милли тикшеренү технология университеты студентына;

21) Мазанова Ксения Николаевнага – Казан (Идел буе) федераль университеты студентына;

22) Миндубаева Алинә Ирек кызына – Россия кооперация университеты филиалы – Казан кооперация институты студентына;

23) Миңнеханова Алия Нәфис кызына – Икътисад, идарә һәм хокук институты (Казан шәһәре) Әлмәт филиалы студентына;

24) Мөхәммәтҗанова Ләйсән Дамир кызына – Казан (Идел буе) федераль университетының Алабуга шәһәрендәге филиалы студентына;

25) Мөхәммәтшина Гөлнур Нургаян кызына – Казан дәүләт технология университеты студентына;

26) Наһриманов Руслан Наил улына – Казан (Идел буе) федераль университеты студентына;

27) Нуриева Ләйсән Камил кызына – Казан дәүләт энергетика университеты студентына;

28) Павлова Екатерина Владимировнага – Казан милли тикшеренү технология университеты студентына;

29) Рәүпов Инзир Рамил улына – Әлмәт дәүләт нефть институты студентына;

30) Рәшитов Рөстәм Рафаил улына – Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университеты студентына;

31) Савин Владимир Евгеньевичка – Казан милли тикшеренү технология университеты студентына;

32) Сәйфетдинов Энгель Альберт улына – Казан (Идел буе) федераль университеты студентына;

33) Сираҗетдинов Руслан Мәгъсум улына – А.Н. Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты – КАИ студентына;

34) Струнская Софья Евгеньевнага – А.Н. Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты – КАИ студентына;

35) Суханов Владимир Андреевичка – Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты студентына;

36) Фәйзерова Фәридә Фәтхулла кызына – Казан (Идел буе) федераль университетының Алабуга шәһәрендәге филиалы студентына;

37) Хәйруллина Алия Галим кызына – Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм академиясе студентына;

38) Харисова Рәсинә Рафис кызына – А.Н. Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты – КАИ студентына;

39) Хәсәншин Гадел Ринур улына – Социаль белем академиясе студентына;

40) Хафизова Ләйсән Рәхимҗан кызына – Н.Г. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе (академиясе) студентына;

41) Шалдымов Владислав Владимировичка – А.Н. Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты – КАИның Алабуга филиалы студентына;

42) Шалдымов Никита Андреевичка – Казан (Идел буе) федераль университеты студентына;

43) Шашина Елена Владимировнага – Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан юридик институты курсантына;

44) Шириева Алсу Камил кызына – Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты студентына;

45) Йосыпова Алинә Фәррат кызына – А.Н. Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты – КАИ студентына;

46) Ягушев Альберт Гадел улына – «ТИСБИ» Идарә университеты студентына;

47) Язолюк Александр Васильевичка – Россия Федерациясе Граждан оборонасы, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казаларны бетерү эшләре министрлыгының Дәүләт янгынга каршы көрәш хезмәте Санкт-Петербург университеты курсантына;

48) Яшина Татьяна Сергеевнага – Әлмәт дәүләт муниципаль хезмәт институты студентына.

3. Урта һөнәри белем дәүләт мәгариф учреждениеләре студентларына:

1) Әхмәтова Линара Роберт кызына – Әлмәт дәүләт муниципаль хезмәт институты студентына;

2) Горчаков Денис Викторовичка – Кама дәүләт автомеханика техникумы студентына;

3) Дадацкий Тимур Сергеевичка – Чаллы педагогия колледжы студентына;

4) Җәббарова Ләйсән Феликс кызына – Алабуга мәдәният һәм сәнгать училищесы студентына;

5) Кудинова Татьяна Викторовнага – Алабуга медицина училищесы (техникумы) студентына;

6) Кузнецова Анастасия Геннадьевнага – Буа медицина училищесы студентына;

7) Степанова Алина Алексеевнага – Түбән Кама нефть химиясе колледжы студентына;

8) Урамова Надежда Николаевнага – Зәй политехник колледжы студентына;

9) Хәбибуллин Рәмис Рәҗәп улына – Габдулла Тукай исемендәге Әтнә авыл хуҗалыгы техникумы студентына;

10) Хәмидуллина Лилия Марат кызына – Казан технология һәм дизайн колледжы студентына.

4. Башлангыч һөнәри белем дәүләт мәгариф учреждениеләре укучыларына:

1) Әгълиева Гөлназ Әлбин кызына – Түбән Кама технология колледжы укучысына;

2) Ахунов Рафил Рифгать улына – Сарман аграр колледжы укучысына;

3) Базеева Татьяна Андреевнага – Алексеевск аграр колледжы укучысына;

4) Дериглазов Артем Сергеевичка – 27 нче һөнәр училищесы (Казан шәһәре) укучысына;

5) Җәббарова Миләүшә Нурислам кызына – Алексеевск аграр колледжы укучысына;

6) Зәйдуллин Борис Юрьевичка – Чаллы шәһәре политехник колледжы укучысына;

7) Меркулов Данил Константиновичка – 41 нче һөнәр колледжы (Казан шәһәре) укучысына;

8) Подовайленко Александр Сергеевичка – Кама политехник колледжы укучысына;

9) Фәсхетдинов Игорь Александровичка – Нефть химиясе һәм нефть эшкәртү техникумы (Түбән Кама шәһәре) укучысына;

10) Чебышева Виолетта Сергеевнага – 41 нче һөнәр колледжы (Казан шәһәре) укучысына.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 25 гыйнвар
№ ПУ-48

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 103. «Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале белән бүләкләү турында

Җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттырудагы казанышлары, Питрәч муниципаль районының социаль-икътисадый һәм мәдәни үсешенә зур өлеш кертүе өчен

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башлыгы – Питрәч муниципаль район Советы рәисе | Насыйбуллин Шәйхулла Галимулла улын |

«Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 25 гыйнвар
№ ПУ-49

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 104. Татарстан Республикасының Азнакай районы Мәндәй авылы территориясендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында

Терлекләрнең котыру авырулы булуы ачыклану һәм аның Татарстан Республикасы торак пунктларында таралу куркынычы белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» Россия Федерациясе Законының 3[1], 17 статьялары нигезендә **карар бирәм**:

1. Терлекләр котыру авырулы булганга аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертергә:

а) Татарстан Республикасының Азнакай районы Мәндәй авылы территориясендә;

б) Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләрендә:

Азнакай шәһәрендәге Яшьләр урамы;

Әлмәт районының Тайсуган авылындагы Сәлахетдинов урамы;

Әлмәт районының Түбән Абдул авылындагы Бакча урамы;

Зәй районындагы Бигеш авылындагы Ленин урамы;

Лениногорск шәһәрендәге Киң урам;

Арча районының Түбән Оры авылы янындагы «ВАМИН Мәрҗани» агрофирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьнең мөгезле эре терлек асрау өчен файдаланылучы территориянең бер өлеше.

2. Әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән территорияләрдә карантин гамәле дәвам иткән вакытта түбәндәгеләр тыела:

йорт хайваннарын сату, аларны әлеге территориядән читкә чыгару һәм кыргый җәнлекләрне (аларны зоопаркларга чыгару өчен, башка районнарда үрчетү максатларында) тоту;

котыру авырулы яисә авыру дигән шик тудыра торган хайваннарны ит өчен сую;

котыру авырулы терлекләрнең сөтен сату, ризыкка куллану һәм хайваннарга ашату;

клиник сәламәт терлекләрнең билгеләнгән тәртиптә пастеризацияләнмәгән сөтен сату, ризыкка куллану һәм хайваннарга ашату;

клиник сәламәт терлекләрнең билгеләнгән тәртиптә дезинфекцияләнмәгән йонын, тиресен әлеге территориядән чыгару.

3. Карантин, зарури чаралар күрү шарты үтәлгәндә, терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагы көненнән ике ай вакыт узгач бетерелергә тиеш, дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән территорияләрдә терлекләрнең котыру белән чирләвен бетерү буенча чаралар планнарын эшләргә һәм расларга, шулай ук аларның гамәлгә ашырылуын тәэмин итәргә.

5. Әлеге Указның үтәлешенә контрольне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына йөкләргә.

6. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 28 гыйнвар
№ ПУ-50

## 105. Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында

Терлекләрнең котыру авырулы булуы ачыклану һәм аның Татарстан Республикасы торак пунктларында таралу куркынычы белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» Россия Федерациясе Законының $3^1$, 17 статьялары нигезендә **карар бирәм**:

1. Терлекләр котыру авырулы булганга иминлексезлек сәбәпле Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләрендә карантин кертергә:

Азнакай шәһәрендәге Гафури урамы;

Азнакай шәһәрендәге Кол Шәриф урамы;

Әлмәт районының Яңа Нәдер авылындагы Куйбышев урамы;

Нурлат шәһәрендәге Совет урамы;

Саба районының Курсабаш авылындагы Гагарин урамы;

Саба районының Түбән Утар авылындагы Муса Җәлил урамы;

Актаныш районы Такталачык авылының Афзал урамындагы 39 номерлы шәхси йорт хуҗалыгы;

Әлмәт шәһәренең Фәхретдин урамындагы 11 номерлы йорт яны территориясе;

Сарман районы Чукмарлы авыл җирлегенең Нарatasты авылыннан төньяк-көнбатыш юнәлештә 500 метр ераклыкта урнашкан 0,5 гектар мәйдандагы җирләре.

2. Әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән территориядә карантин гамәле дәвам иткән вакытта түбәндәгеләр тыела:

йорт хайваннарын сату, аларны әлеге территориядән читкә чыгару һәм кыргый җәнлекләрне (аларны зоопаркларга чыгару өчен, башка районнарда үрчетү максатларында һ.б.ш.) тоту;

котыру авырулы яисә авыру дигән шик тудыра торган хайваннарны ит өчен сую;

котыру авырулы терлекләрнең сөтен сату, ризыкка куллану һәм хайваннарга ашату;

клиник сәламәт терлекләрнең билгеләнгән тәртиптә пастеризацияләнмәгән сөтен сату, ризыкка куллану һәм хайваннарга ашату;

клиник сәламәт терлекләрнең билгеләнгән тәртиптә дезинфекцияләнмәгән йонын, тиресен әлеге территориядән чыгару.

3. Карантин, зарури чаралар күрү шарты үтәлгәндә, терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагы көненнән ике ай вакыт узгач бетерелергә тиеш, дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән территориядә терлекләрнең котыру белән чирләвен бетерү буенча чаралар планын эшләргә һәм расларга, шулай ук аның гамәлгә ашырылуын тәэмин итәргә.

5. Әлеге Указның үтәлешенә контрольне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына йөкләргә.

6. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 28 гыйнвар
№ ПУ-51

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 106. Татарстан Республикасының «Ана даны – Материнская слава» медале белән бүләкләү турында

Балаларын намус белән тәрбияләве өчен

| | |
|---|---|
| Саба муниципаль районының Туктар авылыннан биш бала анасы | Хәйбиева Фәнзия Сөләйман кызын |

Татарстан Республикасының «Ана даны – Материнская слава» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 28 гыйнвар
№ ПУ-52

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 107. Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында

Нефть сәнәгате үсешенә лаеклы өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| «Татех» ябык акционер җәмгыяте генераль директорының беренче урынбасары – баш инженеры, Әлмәт шәһәре | Верия Евгений Ивановичны |

Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләргә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 28 гыйнвар
№ ПУ-53

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 108. «Татарстан Республикасының Атказанган төзүчесе» дигән мактаулы исем бирү турында

Төзелеш тармагы үсешенә керткән өлеше һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| «Кама автомобиль юллары һәм аэродромнар төзү тресты» ябык акционер җәмгыятенең юл-төзелеш җайланмалары буенча баш белгече, Чаллы шәһәре | Григорьев Александр Степановичка |

«Татарстан Республикасының Атказанган төзүчесе» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 28 гыйнвар
№ ПУ-54

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 109. «Татарстан Республикасының Атказанган укытучысы» дигән мактаулы исем бирү турында

Мәгариф өлкәсендәге казанышлары, күпьеллык намуслы хезмәте өчен

| | |
|---|---|
| Казан шәһәре Мәскәү районының «2 нче лицей-интернат» гомуми белем бирү муниципаль автоном учреждениесе биология укытучысы | Маликова Фәридә Әхмәд кызына |

«Татарстан Республикасының Атказанган укытучысы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 28 гыйнвар
№ ПУ-55

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### 110. «Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирү турында

Финанс-икътисад эшчәнлегендәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәтләре өчен:

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Советы аппаратының бухгалтерлык исәбе һәм хисабы бүлеге башлыгы | Ананьева Нина Михайловнага |
| Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы финанс-бюджет палатасы рәисе урынбасары | Журавлева Елена Александровнага |

«Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 ел, 28 гыйнвар
№ ПУ-56

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ
